ПИОНЕР КАЛӘМЕ

АПРЕЛЬ 1940 № 4

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!
ЛЕНИН—СТАЛИН ЭШЕ ӨЧЕН КӨРӘШКӘ ХӘЗЕР БУЛ!

ПИОНЕР КАЛӘМЕ

БАЛАЛАР ӨЧЕН ЧЫГАРЫЛА ТОРГАН АЙЛЫК ӘДӘБИ ЖУРНАЛ. ВЛКСМ НЫҢ ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫ ҺӘМ МӘГАРИФ ХАЛЫК КОМИССАРИАТЫ ОРГАНЫ.

БУ НОМЕРДА:

Орден балкый (Г. Камалов шигыре) 2
Ленин турында хикәяләр (М. Зощенко әсәре, Гумер Хәбиб тәрҗемәсе) 3
Маяковский турында (Н. Асеев мәкаләсе) 12
Прогулкин Влас—ялкау һәм буш-баш (В. В. Маяковский шигыре, Ә. Исхак тәрҗемәсе) 14
Маяковскийга (Фаик Мөхәммәтҗанов шигыре) 16
Куык (М. Җәлил шигыре) 17
Кошлар (Әширә Кәтиева шигыре) 18
Эшсезлек (Эмиль Золя хикәясе, А. Алиш тәрҗемәсе) 19
Кылыч бирегез! (Фалих Сиражиев шигыре) 21
Сау булыгыз, бозлар! (Ф. Саттаров шигыре) 21
Кояш белән бала (Н. Хәмидуллин шигыре) 21
Калкукырда кар беткәч (Мирсәй Әмир хикәясе, П. Новичков рәсемнәре) 22
М. В Ломоносов (Хәмит Кави мәкаләсе) 32
Рәсемнәр.

Тышлыкның беренче битендә: Мәктәп бакчасында. Художник Г. Арсланов рәсме. **Өченче биттә:** Күңелле ял.

Редакциянең адресы: Казан шәһәре, Бауман урамы, 19.
Матбугат йорты (2 нче кат, 5 нче бүлмә).
Телефон № 18—78.

АПРЕЛЬ 1940 № 4

Рәсемдә: ЛЕНИН ОРДЕНЫ. Бу орден 7000 данә ялтыравыклы таштан, 11 квадрат метр зурлыгында итеп эшләнгән.
Фото—Б. Фишман һәм А. Грибовский.
(ТАСС фотоклишесе).

ОРДЕН БАЛКЫЙ

Корыч кебек таза күкрәгеңдә
Алтын орден балкый яктырып,
Җылысын һәм алсу нурын сибә
Кояштан да болай арттырып.

Бабабызның бөек исме анда
Зур хәрефләр белән язылган,
Асыл таштан койган рәсеме аның
Байрак белән урап алынган.

Без беләбез, синең бу орденны
Ничек итеп яулап алганың,
Һәм дошманга каршы нәфрәт белән
Кыю атлап алдан барганың.

Аждаһа күк килгән дошман явын
Яшен суккан кебек иттең син,
Зур таш кебек кара авырлыкны
Геройларча таптап үттең син.

Кайнап торган сугыш кырларында
Җир тетрәтеп утлар уйнаттың,
Дошманны син көлгә әйләндереп
Тузгыттың һәм „сабак“ укыттың.

Йөрәгеңдә сүнмәс эш ялкыны
Торган саен ачык күренә,
Һәм һаман да шатлык белән ярсып,
Дулкын кебек алга үрелә.

Г. Камалов.
Кинопленка ФЗУ мәктәбе.



Ульяновск шәһәрендә (элекке Сембер шәһәре) Владимир Ильич Ленин туган йорт.
Овальдә: В. И. Ленин 4 яштә вакытта.

*** ***

ЛЕНИН ТУРЫНДА ХИКӘЯЛӘР

М. Зощенко

ЛЕНИН НИЧЕК УКЫДЫ

Ленин яхшы укыды, искиткеч яхшы укыды. Ул гимназияне тәмамлаганы өчен алтын медаль белән бүләкләнде.

Югары уку йортында да ул, бәлки, бик яхшы укыган булыр иде. Ләкин, кызганычка каршы, начальниклар аны университеттан чыгардылар, чөнки ул революционер иде. Ә начальниклар мондый кешеләрне дошман күрәләр иде. Патша да революционерларга укырга ирек бирмәде.

Ленингә университетта укырга гомумән рөхсәт бирмәделәр.

Ленин урнында башка бер кеше булса, югары белемсез калган булыр иде. Ләкин Ленин болай калырга теләмәде.

Ул анасына болай диде: „Югары мәктәпне мин, һич шиксез, тәмамлармын“.

Ә вакыт үтеп бара иде инде. Университеттан чыгарылганнан соң ике ел вакыт үтте.

Ниһаять, Ленин министргә заявление бирде. Ул югары мәктәпнең бөтен курсы өчен берьюлы имтихан бирергә рөхсәт сорады.

Министр гаҗәпләнде һәм уйланды: „Ул барлык имтиханнарны берьюлы ничек тапшыра алыр? Югары мәктәптә укымый бит ул. Яхшы. Мин аңа рөхсәт бирим, ләкин ул барыбер имтиханнарны тапшыра алмас“.

Министрдән рөхсәт алгач, Ленин бик нык хәзерләнә башлады.

Ул көннәр буена китаплар янында утырды, укыды, язды, телләр өйрәнде, тәрҗемә итте һәм башкаларны эшләде.

Җәй көнендә бакчада куе юкә агачлары аллеясе арасында ул кабинет ясады. Ул анда җиргә беркетеп өстәл һәм скамья урнаштырды. Һәр иртә саен шунда барды. Анда ялгызы гына, көндезге ашка кадәр шөгылләнде.

Ял иткәннән һәм су коенганнан соң ул яңадан шунда бара һәм тагын өч яки дүрт сәгать буена эшли иде.

Ә кич белән, прогулкадан һәм су коенганнан соң, туганнары аны яңадан китаплар янында күрделәр.

Аның болай бик күп эшли алуын күреп, туганнары да гаҗәпләнделәр, хәт-

та аның сәламәтлегенә зарар килмәсен дип курка да башладылар.

Ләкин Ленин аларга болай диде:

— Әгәр дә кеше дөрес ял итә белсә, гаҗәп күп укый һәм эшли ала.

Һәм, чыннан да, Ленин дөрес ял итә иде. Ул бер сәгат эшли. Аннан соң гимнастика ясый. Аннан соң тагын бер яки ике сәгат буена яза һәм шуннан соң елгага су коенырга йөгерә иде.

Аннан соң, ял иткәч яки урманда бераз йөргәч, китаплары янына кайта һәм тагын укый башлый.

Үзенең җәйге кабинетында, өстәлдән ерак түгел генә урынга, ул үзе өчен турник эшли һәм анда вакыт-вакыт упражнениеләр ясый иде.

Һава яхшы булганда көнгә ул ике яки өч тапкыр коенды. Ул яхшы йөзә иде. Ул үзенең йөзүе белән барлык кешеләрне дә таңга калдыра иде.

Аның бер танышы, үткәннәрне искә төшереп, болай дип сөйли: Швейцариядә бик куркынычлы күл бар, анда һәр вакыт кешеләр баталар иде. Бу күл бик тирән. Анда салкын агымнар һәм упкыннар бар. Ләкин Ленин бу күлдә бер дә курыкмыйча йөзә иде.

Бу таныш кешесе бер вакыт аңар:

— Сак булырга кирәк, биредә кешеләр баталар,—дигән.

— Баталар дисезме? — дип сораган Ленин.—Ярый, без батмабыз.

Һәм шунда ук бик еракка, күз күрә алмаслык диярлек урынга, йөзеп тә киткән.

Су коену һәм физкультура аркасында, дөрес ял итү аркасында, Ленин бик күп эшләде һәм югары мәктәп өчен берьюлы хәзерләнә алды.

Ул шул рәвештә ике ел буена бик нык укыды. Һәм университетның башкалар дүрт ел буена укый торган бөтен курсын шушы вакыт эчендә үтәргә өлгерде.

Ул бөтен имтиханнарны тапшырды һәм беренче дәрәҗәле диплом алды.

Барлык профессорлар да аңа болай диделәр:

— Бу, ис китәрлек эш, сез университетта укымадыгыз ич һәм безнең лекцияләрне дә тыңламадыгыз. Ничек соң сез болай яхшы хәзерләнә алдыгыз? Мәгаен, сезгә кем дә булса ярдәм иткәндер.

Ленин болай дип җавап бирде:

— Юк, мин үзем генә хәзерләндем.

Һәм шуннан соң профессорлар тагын да ныграк гаҗәпләнгәннәр. Министр гаҗәпләнүдән кулларын җәйгән.

Ләкин Лениннең гаять зур акыл иясе һәм гүзәл сәләтле булуы белән бергә, аның гаять зур эшчән булуын да министр һәм профессорлар белмәгәннәр. Ә аның эшкә болай сәләтле булуы физкультурага һәм дөрес ял итүгә бәйле.

Менә шуның өчен дә Ленин үзенең укуын шундый гүзәл уңышлар белән тәмамлый.

КАЙЧАК КАРА САВЫТЫН ДА АШАРГА МӨМКИН

Ленин ундүрт ай буена патша төрмәсендә утырды.

Ул ярым караңгы, кечкенә генә камерада утыра иде. Тимер койка, өстәл һәм табуретка—анда булган әйберләр барсы менә шулар.

Бу камерада Ленин урнында башка берәү утырса, көн буена җылаган һәм газапланган булыр иде. Ләкин Ленин андый кеше түгел иде шул.

Ул бу камерада да көннәр буена эшләде.

Ул иртә белән гимнастика ясый һәм аннан соң китап язарга керешә. Ул биредә бик кирәкле революцион китап—„Россиядә капитализмның үсүе“—дигән китапны яза.

Ә төрмәдә язу эше тыела иде. Анда бер әйбер дә—карандаш та, каләм дә, кара да,—бер нәрсә дә бирмиләр иде. Кәгаз дә бирмиләр иде. Теләсәң ничек яз.

Анда бары тик китаплар гына укырга рөхсәт итәләр иде. Кулга алынучыга туганнары китаплар җибәрә алалар иде.

Һәм Ленин әнә шул китапларга яза башлый. Аны китапта нәрсә булса да язылганлыгын төрмәдәге бер кем дә төшенмәслек итеп язарга кирәк була иде. Чөнки төрмәдә барлык китапларны, туганнарына кайтарып бирүдән элек, тикшерәләр иде. Әгәр дә китапка бер генә сүз язылганны күрсәләр, аны яндыралар иде.

Ә революционерлар сөт белән язарга мөмкин булуын беләләр иде инде.

Әгәр дә кәгазьгә сөт белән язсаң, анда язылган сүзләр бөтенләй күренмиләр.

Ә язылганнарны уку өчен, бу кәгазьне лампа яки шәм өстендә җылытырга кирәк һәм шуннан соң сөт караңгылана башлый, кәгаз өстенә коңгырт хәрефләр килеп чыга һәм анда язылганнарның барсын да укырга мөмкин була.

Ленин китапның кырыйларына һәм юл араларына менә шулай итеп язды. Ә аның туганнары бу турыда беләләр. Китапны кире алгач та, аның битләрен лампада җылыталар, укыйлар һәм күчереп язалар иде.

Ленин төрмәдә үзенең китабын менә шулай язды.

Ләкин мондый эштә дә бик саклык кирәк. Әгәр дә төрмә надзирателе аның болай язуын күрсә, ул вакыт аңа начар булыр иде. Авыруы сәбәпле бирелә торган сөтне дә ул чакта бирүдән туктатырлар һәм Ленинне каты җәзаларлар иде.

Ә надзиратель камерага бик еш керәп йөри. Яки кулга алынган кеше нәрсә эшли икән дип, ишектәге кечкенә тәрәзәдән караштыргалый иде.

Шуннан соң Ленин менә мондый бер әмәл уйлап тапты. Ул икмәктән кара савыты ясады һәм каяндыр табып алган каләмне шуңа манып язды.

Бер вакыт надзиратель акрын гына килеп ишектәге кечкенә тәрәзәдән карый һәм кызыклы бер картина күрә: Ленин язып утыра.

Надзиратель ишекне бик тиз генә ача да камерага керә һәм:

— Сез әләктегез. Минемчә, сез хәзер нәрсәдер яздыгыз,—ди.

Ленин үзенең кара савытын тыныч кына ала һәм аны авызына кабып чәйни.

Надзиратель аңар:

— Сез нәрсә эшлисез! Сез кара савыты ашыйсыз ич,—ди.

Ленин:

— Сез, ахрысы, сукрайгансыз. Бу кара савыты түгел, ә икмәк ич. Менә мин шуны ашыйм,—дип җавап бирә.



Казанда Ульяновлар семьясе торган йортта В. И. Ленин бүлмәсе.

* * *

Надзиратель карый—чыннан да икмәк. Мәгаен минем күзләрем бозылгандыр. Ул миңа кара савыты ашаган кебек булып күренде,—дип уйлана ул.

Һәм шушы уй белән надзиратель чыгып китә. Ә Ленин икмәктән тиз генә икенче кара савыты ясый, аңа сөт сала һәм тагын яза башлый.

Һәм һәр вакытта да, надзиратель килгәндә, Ленин үзенең кара савытын тыныч кына алып, ашап бетерә барды. Кара савыты хәтта тәмле дә була иде, чөнки ул сөт белән икмәк бит.

Ленин төрмәдән чыккач, шаярып, үзенең туганнарына һәм танышларына болай диде:

— Беләсезме, бер вакытны миңа бик шәп үк булмады, ике сәгат вакыт эчендә алты кара савыты ашап бетерергә туры килде.

Барсы да көлештеләр. Эшнең нәрсәдә икәнлеген белмәүчеләр генә гаҗәпләнделәр: кара савытын ничек ашап булсын инде?

Ә туры килгәндә кара савытын да ашап була икән шул.

ЖАНДАРМНАРНЫ ЛЕНИН НИЧЕК АЛДАГАН

Егерме алты яшь тулганда Ленин барлык кешегә дә билгеле революционер иде инде, һәм патша хөкүмәте аннан уттан курыккан кебек, курыкты.

Ленинне патша төрмәгә утыртырга кушты.

Владимир Ильич ундүрт ай буена төрмәдә утырды.

Ә аннан соң, жандармнар аны Сибирьгә сөргенгә җибәрделәр. Һәм анда, Сибирьдәге авылда, Ленин өч ел яшәде.

Ә бу авыл бик еракта, тайга эчендә иде. Анда яхшы бер нәрсә дә юк иде. Аның янында кечкенә генә Шушь елгасы ага. Анда сирәк кенә агачлы кечкенә генә урман да бар.

Ләкин Владимир Ильич үзен мондый күңелсез бушлыкка сөрделәр дип борчылмады. Ул анда бик күп эшләде, революцион китаплар язды, крестьяннәр белән сөйләште һәм аларга үзенең киңәшләре белән ярдәм итте.

Ә буш вакытларында үзенең аү эте „Женька“ белән ауга йөрде, су коенды, шахмат уйнады. Ә шахматларны агач каерысыннан кисеп ул үзе ясады. Ул аларны бик яхшы, бик пөхтә итеп эшләде.

Вакыт сизелмичә үтә бирә. Өч елга якын вакыт үтеп тә китә. Сөргендә торуның соңгы көннәре дә якынлаша.

Владимир Ильич революцион эшне тагын дәвам иттерү өчен кая китү турында уйлый башлый.

Сөргендә торуның соңгы көннәре алдыннан, Ленин торган йортка патша жандармнары килеп керәләр:

— Менә нәрсә. Без хәзер сездә тентү ясыйбыз. Әгәр дә патша хөкүмәте тарафыннан тыелган берәр нәрсә тапсак, сак булыгыз. Ул чакта, азат итү урнына, без сезне бу ерак авылда, аз дигәндә тагын өч елга калдырырбыз.

Ә Ленина тыелган китаплар һәм төрле революцион документлар бар иде. Ә бу китаплар һәм документлар китап шкафының аскы киштәсендә яталар иде.

Менә зур мыеклы, юан жандарм бер кем дә кермәсен һәм чыкмасын дип, ишек төбендә басып тора. Ә кечкенә буйлы, шулай ук зур мыеклы һәм ачулысы бүлмәдә арлы-бирле йөри һәм барлык нәрсәгә дә тыкшына.

Ул өстәлне, комодны, пичне карый һәм кровать астына кереп, анда нәрсә барлыгын тикшерергә дә иренми.

Аннан соң ул шкаф янына килеп:

— Нәрсә соң бу, сезнең шкафта?— дип сорый.

— Бу шкафта минем китапларым,—ди Ленин.

Жандарм:

— Ә менә мин хәзер сезнең китапларны карармын да, аларның нәрсә икәнен күрермен!—ди.

Менә жандарм тикшерүне кайдан башларга—өске киштәдәнме, яки аскы киштәдәнме?,—дип шкаф янында уйлапып басып тора.

Лениннең хатыны, Надежда Константиновна Крупская, бу жандармга карап уйлана:

„Тентүне ул өске киштәдән башласа гына ярар иде. Әгәр дә өске киштәдән башласа, эш яхшы, аннан соң ул тентү ахрында арыр һәм соңгы киштәне игтибар биреп тикшермәс. Әгәр дә ул тентүне аскы киштәдән башласа, ул чак эш начар—нак шушы киштәдә, башка китаплар арасында тыелган китаплар да бар“.

Ленин дә жандармга карап уйлана.

Кинәт Ленин үзендә туган уйдан көлемсерәп, урындык алып килә һәм аны шкаф янына куя. Жандармга карап болай ди:

— Кыска буегыз белән югарыга үрелеп азапланганчы, менә бу урындыкка басыгыз да, китапларымны тикшерә башлагыз. Революционер тарафыннан булган хөрмәтне күреп, зур мыеклы кечкенә жандарм рәхмәтләр әйтә-әйтә, урындыкка басты. Урындыкка менгәч инде ул, билгеле, өске киштәдән тикшерә башлады. Ягни, бу нак Ленин теләгәнчә булды.

Жандармга карап Владимир Ильич көлемсерәде.

Лениннең жандармнан үзе теләгәнчә тикшертә алуын күреп, Крупская да көлемсерәде.

Менә жандарм өске киштәдә казына, һәрбер китапның исмен укый һәм аларны селкеп-селкеп карый. Ә вакыт уза. Китаплар бик күп. Ике сәгат вакыт эчендә жандарм көч-хәл белән генә дүрт киштәне тикшереп чыга алды.

Жандарм бишенче киштәне артык зур игтибар белән тикшермәде. Шуның өстәвенә, ишек янында торучы юан жандарм да уфылдый һәм пошына башлады. Хәтта ул үзенең дустына:

—О х, тенту бигрәк озак бара. Мин ардым һәм ашыйсым да килә,—диде.

Кечкенә жандарм аңар:

— Тиздән ашарга барырбыз. Менә соңгы киштә генә калды. Ярый, бөтен шкафыннан бер нәрсә дә табылмагач, аларның бу киштәләрендә, мәгаен, бер әйбер дә юктыр,—дип җавап бирде.

Юан жандарм да:

— Билгеле, аларда бер әйбер дә юк. Әйдәгез, ашарга барыйк... Кечкенә жандарм, аскы киштәне бөтенләй тикшермичә диярлек, Ленинга болай диде:

— Димәк, без сездән тыелган бер нәрсә дә тапмадык. Хушыгыз.

Шушы сүзләрне әйткәч жандармнар чыгып киттеләр. Алар чыккан ишек ябылу белән үк Владимир Ильич һәм Крупская жандармнарны җүләрлеккә калдырулары белән шатланышып көлештеләр.

ИПТӘШ ИВАНОВ

1917 нче елда, башында Керенский торган Вакытлы хөкүмәт барлык большевистик юлбашчыларны кулга алу турында приказ чыгарды.

Владимир Ильичне кулга төшерә алучыларга хөкүмәт акчалата зур бүләк бирергә вәгдә итте.

Партия Үзәк Комитеты һәм бигрәк тә иптәш Сталин Лениннең Петроградтан китүен таләп иттеләр. Ленин шулай эшләде дә. Ул Разливка китте һәм анда Сестрорецкий заводы эшчесенең йортына урнашты. Ләкин озакка калу Разливта да куркынычлы иде. Тирә якта дачалар. Халык күп. Биредә дә Ленинне танулары һәм аның турында барып әйтүләре мөмкин. Шулай да берникадәр саклык чаралары күрелде: Ленин сакал-мыегын кырдырды.

Тагын да куркынычсызрак урын турында уйланырга туры килде.

Бу печән чапкан вакытларда иде. Һәм Ленин, печән чабучы сыйфатында, Разливның аргы ягына—болынга күчте.

Биредәге урын аулак. Ләкин анда бик тиз генә барып булмый—күл аркылы бары тик көймә белән генә чыгарга мөмкин.

Печән чапкан урынны хәтерләтү өчен, эшчеләр печән чабып зур кибән өеп куйдылар. Һәм Владимир Ильич өчен шалаш кордылар.

Ленин менә шушы шалашта йоклады һәм яңгырдан сакланды. Һава яхшы вакытта, шалаш янында утырып, үзенең атаклы китабын—„Дәүләт һәм революция“не язды.

Ленин ял вакытларында, кулына тырма алып печәннәрне әйләндерде һәм киптерде. Яки күлдә балык тотты.

Мондый тормыш аңа бик ошады. Ул үзен яхшы сизде, вактын шат һәм тыныч үткәрде.

Ләкин болай яшәү озак дәвам итә алмады. Көз якынлашты. Яңгырлар еш кына яуды. Көн иртә караңгылана башлады. Төньякның салкын җиле хәтта шалашка да үтеп керә башлады. Печән чабу вакты да тәмамланды. Биредә озакка калу турында уйларга да мөмкин түгел иде.

Менә шуннан соң Ленинне Финляндиягә күчерү мәсьәләсе хәл ителде. Моның өчен чикне үтәргә кирәк иде. Ә ул вакытларда Финляндия чиге аркылы үтү бик уңай, чөнки Финляндия Россиянең бер кисәге булып санала иде.

В. И. Ленин 1907 нче елның декабрендә Фин заливының бозлары буйлап икенче тапкыр эмиграциягә китә.
Художник Рылов картинасыннан (ТАСС фотоклишесе).

һәм чикне үтеп чыгу өчен документларның тәртиптә булуы җитә иде.

Ленин янына килеп йөрүче эшчеләр аңа таныклык—Сестрорецкий заводы эшчесе иптәш Иванов, Константин Петрович исменә алынган пропуск юнәттеләр.

Билгеле, бу ялган пропуск иде. Бу пропускка, законсыз рәвештә, бер комиссариатның печәте басылды. Ә фоторәсем өчен Ленингә йөзенә грим салырга туры килде. Ул парик, тузып беткән кепка иске пальто киде.

Шулай итеп, бу пропусканы алган көннән, Ленин иптәш Иванов дип йөртелә башлады.

Иптәш Иванов чикне куркынычсыз гына үтеп чыга алсын өчен, эшчеләр барлык юлларны да күзәтә башладылар.

Ләкин бу эш гадәттән тыш кыенлашып китте.

Чик сакчыларының һәрбер документны гаять зур игтибар һәм шикләнү белән тикшерүләрен эшчеләр күрделәр. Җитмәсә тагын, документын күрсәтүченең йөзен андагы фоторәсем белән бик нык чагыштырып карыйлар. Ул гына да түгел, барлык чик сакчысының кулында эшчеләр Ленин рәсме булуын күрделәр.

Ленинне тоту турында чик сакчылыгына приказ алынганлыгы да беленде. Ленинне тотучыларга вагдә ителгән акчалата бүләк чик сакчыларын бу эшкә бөтен көчләрен куярга мәҗбүр иткән.

Ялган документ белән иптәш Ивановның чик аркылы үтеп чыга алмаячагын эшчеләр аңладылар. Тагын башка берәр чара уйлап карарга кирәк иде.

Эшчеләр бер машинист белән сөйләштеләр. Ә ул Ленинне Финляндиягә паровозга утыртып чыгарырга булды.

Моның өчен Удельная станциясенә барырга, билгеләнгән көндә һәм сәгаттә бу машинист алып барасы паровозга яшренеп кенә утырырга кирәк иде.

Бу эш, билгеле, куркынычлы. Шулай да бу куркынычлыкка барырга туры килде.

Удельнаяда төн кунарга һәм икенче көнне инде, нак машинист белән сөйләшкәнчә эшләү өчен, Разливтан Белостров тармагына кадәр килергә, анда очраган беренче поездга утырып алар Удельная станциясенә кадәр барырга булдылар.

14 нче августта кич белән дүрт кеше, аларның берсе Ленин, яки, дөресрәге иптәш Иванов юлга чыктылар.

Лениннең атаклы шалашы еракта калды.

Башта алар урман аша тар сукмак буйлап бардылар.

Кинәт караңгылана башлады. Юлчылар сукмактан читкә чыктылар һәм аны югалттылар. Йолдызларга карап көнчыгышка таба киттеләр.

Кинәт ачы төтен исе аңкыды. Күрәсең, кайдадыр торф яна.

Ачы ис көчәйде. Сулыш алу кыенлашты. Аяк астында торф янганлыгы беленде.

— Пожар эченнән тизрәк чыгарга кирәк, чөнки торф җир астында яна, һәм җирнең өске катлавы кешеләрне күтәреп тора алмаслык хәлгә килә. Яна торган торф эченә кешеләрнең төшеп китү вакыйгаләре дә очрый,— дип сөйләде бер эшче.

Юлчылар сул яккарак киттеләр, ләкин пожар бөтен урында да бар кебек тоелды.

Менә төтен азайды, юлчылар елга янына килеп чыктылар.

Бу Черная елгасы иде. Җәй көне аны бик иркен рәвештә ерып чыгалар. Ә хәзер ул, яңгырдан соң, тирәнлеге билгеле булмаган зур елгага әверелгән. Безнең юлчыларыбыз нәрсә эшләргә һәм ничек үтәргә белмичә, аның янында тукталып калдылар.

Ленин бөтен юл буена үзен искиткеч дәрәҗәдә тыныч тотты, ә елга янына килгәч, пожардан соң салкын ваннага керү файдалы дип шаярта һәм көлә башлады. Ул бик тиз генә чишенде дә, киемнәрен баш өстенә куеп, беренче булып суга керде.

Кырык җиде яштәге Лениннең яшьләрчә дәрт белән елганы ерып чыгуын карап тору бик кызыклы тоелды. Су аның күкрәгенә кадәр, ә урны-урны белән муенына кадәр җитсә дә ул ышанычлы атлый иде.

Юлчылар елганы тыныч кына үтеп чыктылар һәм, киенгәч, тагын үз юлларын дәвам иттерделәр. Көтелмәгәндә генә урман бетте, юлчылар ниндидер канав янына килеп җиттеләр.

Алда тимер юл. Сул якта станция йорты күренә.

Бу Дибуны станциясе иде.

Белоостровка иң якын станция шушы иде. Биредә, чик полосасында, үзеңне сак тотарга кирәк. Чыннан да, платформа буйлап юнкерлар һәм коралланган сакчылар йөреп торалар.

Юлчылар канав буена яттылар да, нәрсә эшләргә кирәклек турында— Песочная платформасына кадәр җәяү бару, яки поездны көтү турында—уйлаша башладылар.

Бер эшче билет алырга, поездның кайчан китүен һәм аның бүгенме китүен белешергә дип станциягә китте. Чөнки вакыт төнге сәгат берләр тирәсе иде.

Ләкин бу эшчене юнкерлар шул вакытта ук тотып алдылар. Алар, козгыннар кебек, аңар ташландылар. Һәм аны вокзалга өстерәп алып кереп тә киттеләр.

Ләкин эшченең документлары тулысынча тәртиптә, аның өчен борчылмаска да мөмкин иде. Шулай булып чыкты да: иртә белән, сорау алганнан соң, аны азат иттеләр.

Канавда ятучылар ул юк арада поездны көтәргә булдылар.

Бәхеткә каршы тиздән поезд да килде, һәм Ленин ике юлчы белән вагонга тыныч кына менеп утырды.

Вагон бөтенләй буш диярлек иде. Юлчылар җайлап кына урындыкларга урнаштылар. Бик арылган. Черем итеп аласылары килде. Кинәт вагонга фонарь тоткан кондуктор керде һәм билетлар күрсәтүне сорады.

Эш начар булып бетәргә мөмкин иде. Кондуктор пассажирларны якын станциядә сакка биреп калдыра ала иде. Ләкин кондуктор сирәк очрый торган киң күңелле яхшы кеше булып чыкты. Пассажирларның билетлары юклыгын белгәч, кондуктор ни өчендер шатланып китте һәм куяннар да минем өчен, башка пассажирлар кебек үк, кешеләр бит. Мин куяннарга һәр вакыт яхшы караштa булам, батырлыклары өчен аларны хөрмәтлим, дип үткен сүзләр сөйли башлады.

Ленин көлә башлады, ләкин сакланып көлде һәм кондуктор фонаре белән яктыртып карамасын дип куркып, бер кулы белән йөзен дә каплады.

Ә кондуктор инде политик мәсьәләләргә күчте һәм үзенчә немец шпионы дип уйлаган кешесе—Ленин турында да сүз башлады.

Эшчеләр кыздылар һәм моның хезмәт ияларе юлбашчысы турында Вакытлы хөкүмәт тарафыннан таратылган ялган булуын кондукторга аңлата башладылар. Һәм кондуктор белән шулай сөйләшә торгач, безнең юлчылар Удельнаяга барып та җиттеләр.

Киң күңелле кондукторның кулын кысып, бер кемнең дә күзенә чалынмыйча гына, Ленин үзенең иптәшләре белән йоклау өчен билгеләнгән урынга китте.

Ленин янындагы юлчылардан берсенең квартирасына килеп җиткәндә сәгат төнге өчләр чамасы иде инде.

Билгеләнгән шарт буенча ишек шакыдылар. Ишекне бер хатын ачты.

Ленин эшченең җинак бүлмәсенә керде. Өстәл, урындык, һәм ярлы гына кровать—анда булган әйберләрнең барсы менә шулар.

Хуҗа һәм хуҗа хатын Ленинне үзләренең урнына ятарга кыстый башладылар. Ләкин Ленин риза булмады.

В. И. Ленин броневикта. Скульптор Манизер эше.
(ТАСС фотоклишесе).

Ленин кесәсеннән газета алып идәнгә җәйде дә, пальтосын баш астына салып, тиздән йокыга китте.

Аның белән килүчеләр дә йокладылар. Бары тик хуҗа хатыны гына йокламады—ул аларның тыныч йокыларын саклады.

Икенче көнне кичкә таба яңа юлга, тагын да куркынычрак юлга, хәзерләнә башладылар.

Ленинне паровозга утыртып алып барырга ышандырган машинист төнге, иң соңгы поездны Петроградтан алып килә иде.

Поездга бик сакланып утырырга кирәк иде.

Ленин үзенең ике иптәше белән кичке сәгать унберда станциягә китте.

Поезд килгәч кенә станциядә күренергә дип сөйләшенелде.

Менә поезд да килде.

Шул ук вакытта Ленин паровоз янына килде һәм баскычларга басып, нак кочегардай, тиз генә, җиңел генә менеп тә китте. Аңа бер кем дә игтибар бирмәде. Бер минуттан соң паровоздан чын кочегар төште, алдан сөйләшеп куюя буенча, ул вагонга күчәргә тиеш иде. Бу кочегар тыныч кына һәм бер нинди каушаусыз гына вагон янына килде һәм аның эченә кереп китте. Хәзер барсы да тәртиптә иде.

Ленинне озатучы эшчеләр иркен сулыш алдылар. Ә моңа кадәр алар пальто кесәләрендәге револьверларын кысып тотып, беренче вагон янында басып торалар иде.

Эш барып чыкмаган хәлдә, Ленинне тотарга маташучыларга атарга карар ителгән иде.

Ләкин бу операция көтелгәннән дә яхшы булып чыкты.

Эшчеләр кочегар артыннан вагонга керделәр.

Поезд гудок бирде дә кузгалып китте.

Көлемсерәп һәм күзләре белән топкага таба ымлап машинист, ачулы йөзле һәм батыр карт фин, Ленингә эш белән шөгыльләнергә кушты.

Ленин топканы ачты да, ут эченә утыннар ыргыта башлады.

Машинист зур канәгатьләнү белән башын селекте.

Паровоз тавышы астында сөйләшү кыен һәм тәртип буенча да ярамый иде. Бары тик бер станциядә машинист Лениннән, сез үзегезне бирeдә яхшы сизәсезме?—дип сорады. Ленин аңа, бик яхшы дип җавап бирде.

Поезд Белоостровка бер нинди тоткарсыз килеп җитте.

Документларны тикшерү башланды.

Вагоннарның барлык ишекләре дә ябык иде.

Бу хәл эшне кыенлаштырды. Берәр төрле бәлә була калса иптәшләре Ленингә вактында ярдәм күрсәтә алмаслар иде.

Ләкин машинистта яхшы идея туды.

Охрананың паровозга килүен күреп, машинист шул ук минутта паровозны вагоннардан ычкындырды һәм бөтен ход белән су алырга китте. Ун минутлар чамасы су алып торды.

Менә инде ике звонок та булды, ә паровоз һаман да су краны янында тора. Ниһаять, өченче звонок биргән вакытта гына паровоз состав янына килде.

Шул ук минутта паровоз составка беркетелде һәм поезд кузгалып та китте.

Станция дежурные мондый тәртипсезлекне күреп, машинистка бармак янады.

Чыннан да—кран янында ун минут тору һәм бары тик соңгы минутта гына состав янына килеп җиту ярый торган эшме соң? Охрана да үзенә кирәкле эшне башкарырга өлгерә алмады бит.

Поезд үзенең тизлеген көчәйтеп алга ыргылды.

Тагын берничә ун километрлар—аннан соң Финляндия башлана.

Ленин топка капкачын ачып, тиз-тиз утын ыргытып торды.

Поезд бер сәгаттән соң Териокига якынлашты.

Билгеле, бу урында да саклык кирәк—Фин полициясе йокламый. Шулай да Ленин биредә бик үк куркыныч астында түгел иде.

Ай ярым буена диярлек Ленин Финляндиядә яшәде. Башта Териоки янындагы аулак авылда, аннан соң Гельсингфорста һәм, ниһаять, Выборгта торды.

Ленинград белән элемтә яхшы куелган иде. Лениннең барлык боерыклары бик тиз тапшырылдылар. Ләкин Лениннең Финляндиядә торасы килмәде. Хәл иткеч көннәр якынлашканга күрә, ул Петроградка ашыкты.

Сентябрь ахырларында Ленин Финляндияне ташлап китәргә карар итте. Ленинне Финляндиягә китерүче шул ук машинист, аны паровозга утыртып яңадан Петроградка алып кайтты.

ЛЕНИНГӘ ҺӨҖҮМ ИТҮ

Лениннең дошманнары бик күп иде. Бөтен тормышны яңабаштан төзәргә теләгәнлеге өчен аның дошманнары күп булды.

Ул барлык эшләүче кешеләрнең дә бик яхшы яшәүләрен теләде. Ул эшләмәүчеләрне бер дә яратмады. Ул аларга карата болай диде:

— Әгәр дә эшләргә теләмәсәләр, гомумән алар бер нәрсә дә ашамасыннар.

Ә бу бик күпләргә ошамады. Һәм Лениннең дошманнары аны ничек кенә булса да үтерергә теләделәр.

Хезмәт ияләренең бөек юлбашчысы Владимир Ильич Ленинне үтерү өчен алар явыз бер хатынны ялладылар.

Алар аңа агулы пуляләр белән корылган револьвер бирделәр. Һәм бу явыз хатынга: „Заводка бар, анда Ленин речь белән чыгачак. Ул үзенең речен тәмам иткәч, залдан чыгар. Син аның янына кил дә, аңар өч яки дүрт тапкыр ат“,—диделәр.

Ул хатын шулай эшләде дә. Ул кара күлмәк киде, револьвер алды һәм Ленин чыгыш ясаячак заводка китте.

Ленин үзенең речен тәмамлап ишек алдына чыккач, матрос киеменә киенгән ниндидер кеше ишек янында юри егылды. Ул моның белән Ленин артыннан килүче барлык эшчеләрне тоткарлап торды.

Шуның аркасында Ленин ишек алдына үзе генә чыкты һәм утырырга дип автомобиль янына килде.

Кара күлмәк кигән хатын шул ук минутта Ленин янына килде дә аңа револьвердан дүрт тапкыр атты.

Дүрт пулянең икесе Ленингә тиде һәм Ленин каты яраланып егылды: аның үпкәсе үтәли тишелгән һәм кулы яраланган иде.

Бу хатын кача башлады, ләкин аны тоттылар, һәм төрмәгә озаттылар.

Эшчеләр йөгерешеп Ленин янына килделәр, аларның бик күпләре җылыйлар иде, алар Ленинне күтәреп алдылар да автомобильгә утырттылар.

Автомобиль кузгалып киткәч, эшчеләр Лениннең пальтосын һәм пиджагын салдырып алдылар һәм кан күп акмасын дип аның кулын җеп белән бәйләделәр.

Машина Кремльгә керде, Ленин квартирасы алдына туктады.

Авыр яраланган Владимир Ильич зур кыенлык белән генә машинадан төште һәм ул егылмасын дип кешеләр аны култыкладылар.

Эшчеләр йөгерешеп килделәр һәм алар Ленинне квартирасына күтәреп кертергә теләделәр.

Ләкин Ленин аларга моны эшләргә рөхсәт бирмәде. Ул болай диде:

— Юк, мине күтәреп илтергә кирәкми. Мине күтәреп керүне сеңлем һәм хатыным күрер һәм минем хәлем начар дип уйларлар. Аларны борчымаска кирәк.

Шушындый куркыныч моментта Лениннең үзе турында уйламыйча, ә башка кешеләр турында кайгыртуы җыелган кешеләрне гаҗәпләндерде.

Ленин текә баскыч буйлап өченче катка үзе күтәрелде. Дөрес, аны ике яктан култыклап бардылар, ләкин шулай да ул югарыга үзе менде.

Шунда ук яхшы врачларны чакырттылар. Хәле бик авыр, пуляләр агуландырылган булганнар һәм аның каны агулануы да мөмкин диделәр врачлар.

Ләкин Лениннең гүзәл тазалыгы аңар авыр яраланудан соң да сәламәтләнергә ярдәм итте.

Ай ярымнан соң инде Владимир Ильич Ленин яңадан эшли башлады.

Гомәр Хәбиб тәрҗемәсе.

МАЯКОВСКИЙ ТУРЫНДА

„Маяковский безнең совет эпохасының иң яхшы, иң талантлы шагыйре булды һәм шулай булып кала".

И. Сталин.



Владимир Владимирович Маяковский— безнең, совет заманының иң яхшы, иң талантлы шагыйре. Ул Грузиядә, Кутаиси шәһәре янындагы Багдади авылында туды. Аның әтисе урман каравылчысы иде. Маяковскийнең бала чагы иркенлектә, яшеллекләр арасында, зәңгәр күк астында, шаулап ага торган Рион елгасы буенда үтте. Ул каты табигатле, гади кешеләр арасында — аучылар, виноград бакчаларында эшләүчеләр, иген игүчеләр арасында үсте. Аның әтисе Владимир Константинович табигатьне ярата һәм аңлый; урман карап йөргән вакытларда нәни Володяне дә еш кына үзе белән бергә алып йөри иде. Аларның тирә-юнендә зур, куе наратлар, ак чыршылар, күк агачлар, чинарлар үсеп утыралар. Куе ботаклар арасында кошлар сайрый. Килбәтсез рәвештә чайкалып баручы аю аларның юлы аша уза. Куркынычлы хәлләрдә курыкмаска, кыенлыкларны җиңәргә Маяковский кече яштән үк өйрәнеп үсте.

Аларның семьяләре ярлы, ләкин күңелле. Өйгә һәр вакыт яшьләр җыела. Люда һәм Оля исемле ике кыз туганы яш ягыннан олырак булсалар да, гәүдә ягыннан һәм хәрәкәтләренең кыюлыгы ягыннан Володя алардан калышмады. Ул компанияне үтә алмаслык чытырманлыклар арасына алып керә; күңел ачарга, прогулкага чыккан вакытларда ул, тауның сөзәк урыннары буйлап, түгәрәк шома таш өстенә утырып, Рион елгасына туп-туры шуып төшә; балчыктан эшләнгән гаять зур кувшиннарның эченә керә. Ә бу кувшиннарга виноградчы грузиннар яңа гына ясалган аракыны ачытыр өчен салалар. Маяковский шундый кувшин эченә кереп шигырьләр укырга ярата иде. Биредә тавыш искиткеч яңгыравыклы булып ишетелә. Еракеракларга җитә ала торган көчле итеп кычкырып сөйләшүгә, сүзләрнең һәм шигырьләрнең яңгыравына мәхәббәт шагыйрьдә менә шулай туды.

1905 нче елда бөтен Грузия кузгалды. Патша Россиясенең бер чигеннән икенче чигенә кадәр җәелгән революцион хәрәкәткә грузин халкы да бердәм рәвештә кушылды. Мохтаҗлык һәм хокуксызлык белән буылган эшчеләр һәм крестьяннар царизмга һәм буржуазиягә каршы күтәрелделәр.

Подпольедәге түгәрәкләрнең эше тагын да җанланды, революцион партияләрнең брошюралары, возваниеләре кулдан-кулга йөреп укылды.

Бу вакытта Маяковский Кутаиси гимназиясендә укый иде әле. 1905 нче елга кадәр, 1 нче классларда, ул отлично билгеләр алып, яхшы укыды. Бары тик үз-үзен тоту һәм дин дәресе буенча гына начар билгеләр алды. Маяковскийның алган билгеләре күрсәтелгән уку көндәлекләре хәзер дә сакланалар. Революцион 1905 нче елда Маяковскийнең уку буенча билгеләре түбән төшүен бу көндәлекләр ачык күрсәтәләр. Уку турында уйларга туры килми. Москвада укучы апасы Людмила Владимировнага язган хатлары бу вакытларда Маяковскийнең нәрсә белән шөгыльләнгәнен безгә сөйлиләр. Ул Кутаисидагы вакыйгалар турында, Гуриядәге восстание турында яза. Гимназистларның ничек

восстание ясауларын, училище алдына пушкалар куелуын яза. Үзенә революцион китаплар һәм брошюралар җибәрүләрен сорый.

1906 нчы елда аның әтисе, күгәргән булавка белән очраклы рәвештә җәрәхәтләнеп, каны агуланып үлә. Тәэсирләнүче малайга бу хәл бик нык йогынты ясый. Куркыныч тудыруы мөмкин булган бәләләргә карата ул гомере буена шикләнеп карады. Бик кыю һәм хәл итүчән, зур тәвәккәллектән курыкмаучан, янаучы куркынычларга каршы баручан бу кеше вак-төякләргә карата бик нык сакланучан һәм шикләнүчән иде. Ул, мәсәлән, үз күз алдында юылмаган стаканнан бер вакытта да су эчми иде. Кечкенә генә сабын савытын ул үз янында йөртә һәм билгесез кеше белән күрешкәннән соң ул кулын юарга китә иде.

Әтисе үлгәннән соң Маяковскийләр семьясе урман каравылчысы өчен эшләнгән квартирадан мәхрүм ителә. Укуны тәмамлау өчен Москвага күчәргә карар бирәләр. Биредә яшәү өчен акча табу турында уйларга туры килде. Кутаисидан укырга дип килгән студентларны тору өчен үз бүлмәләренә урнаштыралар. Болар шул ук революцион яшьләр иде. Маяковский аларның мәхрүмлекләр һәм куркынычлар белән тулы булган тормышларын күрә, ул вакытта яшәп килгән стройның гаделсезлеге турында аларның бәхәсләрен тыңлый һәм революцион эштә үзе дә катнаша. Ул вак-төяк йомышларны үти, листовкалар, подпольедә чыккан газеталар, брошюралар тарата. Аны кулга алалар һәм алты ай буена Бутыр төрмәсендә тоталар. Биредә дә ул бик күп укый һәм тормыш турында уйлый. Кешелек тормышы өчен кирәк булганның барысын тудырып та, үзләре өчен аннан бер нәрсә дә диярлек ала алмаучы ярлылар-эшчеләр ягында булырга дип кискен рәвештә үз-үзенә сүз бирә.

Маяковский рәсем ясарга сәләтле иде. Ул рәсем ясаучылык училищесенә укырга керергә карар бирә. Анда уку срогы бары тик 3 кенә ел. Башка уку йортларына керү өчен кешенең политик ышанычлылыгы турында патша полициясе тарафыннан бирелә торган таныклык язуы да биредә соралмый. Ә Маяковский кулында исә мондый язу юк. Җансыз натураның бер туктаусыз рәсмен төшерү Маяковскийне борчый. Ләкин ул искусство турында училищедә укытканнан да күбрәк белүче интәшләр белән таныша. Алар Маяковскийне рәсем ясаучылыктагы, поэзиядәге яңа агымнар белән таныштыралар. Бу кешеләр арасында иң күренеклесе—Д. Д. Бурлюк. Маяковский аның белән дуслаша. Укыту методына каршы аның белән бергәләп протест ясый. Кискен протестлар ясау, турылык һәм кыюлык өчен аларны училищедән чыгаралар.

Электә дә шигырьләр язучы Маяковский инде хәзер үзендәге уйларны һәм хисләрне гәүдәләндерү өчен яңа сүзләр таба. Ул үзенең бу яңа шигырьләрен, аның зур шагыйрь булачагын шул вакытта ук күрә алган Бурлюкка укый. Биредә Маяковский үзенең язмышы—революцион шагыйрь булу икәнен күрә. Менә шул вакыттан башлап ул кешеләргә, кешеләр массасына тирәнрәк якын килү юлларын эзли.

Шул вакытта Маяковский тирә-юндә хөкем сөрүче гадәт-йолаларга сукыр килеш буйсынуны, хәрәкәтсезлекне, оятсыз чибәрлекне җимерү һәм хурлау өчен рәсем ясаучылык һәм поэзия белән шөгыльләнүче яшьләрнең алдында бара. Бу яшьләр үзләрен „футуристлар“ дип атыйлар иде. Футуристлар—ул замандагы стройның озак яшәвенә ышанмаучы, ләкин яңаны табу һәм гәүдәләндерү өчен суратләү чаралары эзләп таба алмаучы яш интеллигентларның группасы иде. Шуңа күрә алар күпчелек очракларда искене инкар итү белән шөгыльләнделәр. Шул вакытта Маяковский пролетариат искусствосы өчен хас тел табу турында уйлады. Ләкин ул бары тик Бөек Октябрь Революциясеннән соң гына үзенең эзләнүләрен чын-чынлап башлап җибәрә алды.

Октябрьдән соң ук Маяковский революциягә хезмәт итә башлады. Ул безнең илнең дошманнарын тар-мар итә торган шигырьләр язды. Революцион хәрәкәт һәм аның җитәкчесе Владимир Ильич Ленин турында бөек поэма тудырды. Советлар Союзы тормышындагы иң әһәмиятле моментларга карата ягымлылык, кайгыртучанлык һәм мәхәббәт белән тулы йөзләрчә шигырьләр яза. Үзенең куәтле тавышы белән ул катнашмый калган бер генә вакыйга дә юк. Башка шигырьләргә ошашлы булмаган, үзенең көчле һәм кыю шигырьләрендә ул безнең бер генә шатлыгыбызны да, бер генә кайгыбызны да төшереп калдырмады.

Аның иҗады безне көрәшкә һәм җиңүгә рухландыра!

Н. Асеев.



В. В. Маяковский балалар арасында

***

В. В. Маяковский

ПРОГУЛКИН ВЛАС— ЯЛКАУ ҺӘМ БУШ-БАШ

***

Прогулкин Влас—
иркә малай ул.
Йокларга ятса,
журнал ала ул.
Журналда—анда
бик кызык бар да,
— укып чыгам,—ди,—
хет шартласам да!
Әткәсе дә бар,
әнкәсе дә бар,
Йоклата алмый
ләкин һич алар.
Йоклап китә ул
тик таң алдында,
Башка балалар
торган чагында.
Башка балалар
инде чәй эчә,
Аны уятсаң,
ябына төшә.
Мәктәпкә китә
башкалар анда,
Ә ул маташа
кран янында.
Мәктәптә, диеп,
йокы алмасын,
Юа борынын,
чылата башын.
Ашамый-эчми
чыгып китә ул,
Арган гәүдәсен
көчкә тота ул.
Бераз бара да,
туктый ул шунда:
Вывеска күрә
бер магазинда.

Нигә бирелгән
белем аңарга!
Кирәк бит моны
укып карарга!
Бик озак карый
ул вывескага,—
„Куафер Симон“
дигән сүз чыга.
Кирегә укый
аны шунда ук,
Алай укыла:
„Номис рефаук“,
Уйлап торгачтан
бер биш минутлап,
Тагын алгарак
китә ул атлап.
Өченче катта
шунда ул күрә:
„ТЭЖЭ“ дигән бер
вывеска тора.
Укып китә дә,
бер өч минутлап
Витрина карап
тора ул туктап.
Җитә ул шулай
мәктәпкә барып,
Ләкин килгән ул
шактый соңгарып,
Бикләнгән ишек
күренә Власка,—
Керә алмый ул
инде класска!



— Керсәм дә, чыкмас
бер нинди эш,—ди.
„Уйныйм булмаса,
акча чөеш“,—ди.
Берәр тиеннән
оттыра бишне,
Калдырмый ләкин
бу хәлдә эшне.
Кыскасы, сизми
ул шулай кызып,
Өч сәгат вакыт
киткәнен узып.
Мондый чакта соң
нихәл итәргә?
Нәтиҗә ачык:
кайтып китәргә!
Чыраен сыта
күрсеннәр диеп
Әти-әниләр,
күршеләр диеп.
— Балам,—ди алар,—
ни булды сиңа?
— Баш авыртуы
килде, ди, миңа.
Авырта минем
башым шул чаклы,
Кайтып киттем мин
ташлап сабакны.
Хат язызыз, ди,
укытучыга,

Шулай газаплап
йончытучыга.
Мәктәпкә илтә
хатны ул үзе,
Шуннан бик озак
күренми эзе.
Кыскасы, үсә
шул хәлдә Влас,
Булып кала ул
ялкау һәм буш-баш.
Белеме аның
шул кадәр азга,
Аны һич кайда
алмыйлар ВУЗ га.
Шунда заводка
көчкә генә ул,
Кара бер эшче
булып керә ул.
Заводта да ул
һаман бер төсле,
Дәвам иттерә
шундый ук эшне:
Башкалар эшли
гөр килеп, ә ул
Ясый да тора
һаман прогул.

Кыскасы, шулай
бер ай узгачтан,
Прогул өчен
сөреләә заводтан,
Кайгыдан Влас
пивнойда ята,
Төпсез кружкада
мыек чылата.
Дуңгыз күк, ауный
койма буенда,
Буялып, катып,
ята ул шунда.
Ә сез, балалар,
алай булмагыз,
Мәктәпкә йөреп,
дәрес тыңлагыз.
Китаплар белән
коралланыгыз!
Акылны алга
алып барыгыз.
Тик мәктәп кенә,—
тотыгыз истә,—
Шатлыклы көнгә
кешене илтә.

Ә. Исхак тәрҗемәсе.

—★—

Маяковскийга

Дошманнарга каршы сөңге булып
Хезмәт итте синең җырларың.
Үз сыйнфыңа турылыклы булдың,
Җылы караш белән елмайдың.

Үтәр менә шанлы күп гасырлар,
Илебез саклар синең исмеңне,
Һич онытмас туган илең халкы
Хезмәт улын—бөек кешене!

Фаик Мөхәммәтҗанов.



М. Җәлил.

Илдар чыкты урамга,
Куык белән уйнарга.
Очып китте куыгы
Ул каранып торганда.
Җилләр килеп җиттеләр,
Алай-болай иттеләр
Һәм куыкны һавага
Алып менеп киттеләр.
Күрәсеңме куыкны,
Үтеп китте кыекны!
Шуны күргәч Илдарның
Кинәт күңле боекты.
Җыларга да белми ул,
Көләргә дә белми ул,
Күзен алмый куыктан,
Нишләргә дә белми ул.
Менә халык җиналды,
Тулып китте йорт алды.
Кайсы карый югары,
Кайсы назлый Илдарны.
Куык оча бик җитез,
Күтәрелә шундый тиз!..
Менгән саен кечрәя,
Чак аера инде күз.
Бар да карый куыкка,
Күңелле дә, кызык та!
— Карагыз, дип, карагыз,
Хәзер җитә болытка!..

———

Илдар тора аптырап,
Иреннәре калтырап.
Килеп басты янына
Бер очучы лейтенант.
Шуны күргәч Илдарның
Йөзе кинәт ачылды.
Һәм шатланып ул аның
Җиңенә килеп асылынды:
— Абый, син бит очучы!
Самолетка утырчы!
Күктән минем куыкны
Табып җиргә төшерче!
Самолетта син аны
Бик тиз куып җитәрсең.
Куып җиткәч куыкны,
Миңа хәбәр итәрсең.
Минем куык болытка
Барып кергәндер инде.
Су үтмәсен куыкка,
Абый, тизрәк бул инде!..

———

Көлештеләр барсы да,
Очучы да елмайды,
Утыртты да алдына
Кочаклады Илдарны:
— Очуын мин очармын,
Очу ул бик кызыклы!
Ләкин мин бит танымам
Күктә синең куыкны.
Тиздән үзең үсәрсең,
Өйрәнерсең очарга.
Һәм менәрсең һавага
Куыгыңны тотарга.
Үзең аны тиз танып
Очып куып җитәрсең.
Самолетыңа тагып,
Җиргә алып төшәрсең.
Илдарга бу ошады,
Чын күңелдән ышанып:
„Ярый, диде, алайса,
Үскәч үзем очармын.
Өйрәнермен очарга
Һәм табармын куыкны“.
Ул очучы булырга
Уен шулай ныгытты.
Илдар кич тә, көндез дә
Күккә карый моңаеп.
Уйлый, аның куыгы
Һаман шунда, тора, дип.

Ул очучы булырга
Көн дә антын яңарта.
Белемгә һәм эшкә дәрт
Үсә көн дә аңарда.

Еллар үтәр; билгеле,
Куыгы аның онтылыр.
Тик онтылмас очуга,
Яңалыкка омтылу.

Илдар үсәр, һәм булыр
Илнең батыр кешесе.
Иң җитез һәм иң биек,
Иң ерак очучысы.

Табалмаса табалмас
Юкка чыккан куыгын.
Ләкин үскәч ул табар
Күктә очу кызыгын.

Табар җиңү шатлыгын,
Табар үсү тойгысын.
Биеклеккә омтылу—
Бизәр аның тормышын!

КОШЛАР

Матур тамчылар урамда тама.
Кояш җылыта, гөрләвек ага.
Кыш буе бөрешеп, туңып очучы,
Безнең чыпчык та булды бит җырчы:
Чирик, чик-чик; чирик, чик-чик!
Чирик, чик-чик; чирик, чик-чик!
Җылындым бит, җылындым бит,
Җылындым бит, җылындым бит.

Соры муенлы усал чәүкәләр—
Абзар башында киңәш итәләр:
Чар, чар дип, чар, чар дип!
Чар, чар дип, чар, чар дип!

Күк күгәрчен дә канат кагынды,
Ул да бит язны, өзлеп сагынды.
Күңелле итеп, гөр-гөр гөрләде,
Кояш җылысын мактап сөйләде.



Өй түбәсендә, абзар башында—
Яңгырый җырлар ишек алдында.
Кара каргалар бүген килделәр,
Юлга тезелеп хәбәр бирделәр:
— Менә без кайттык ерак илләрдән,
Сәлам китердек җылы җирләрдән.
Без кайткач инде озак та тормас,
Салкыннар бетәр, карлар да яумас.
Кар, кар, яхшы хәбәр бар.
Кар, кар, яхшы хәбәр бар.

Ике сыерчык соры борынлы,
Эзлиләр оя, алар матурны.
— Сарай башында—озын колгада
Сырлы оя бар, куныгыз шунда.
Алар кундылар, сайрап алдылар,
Соңыннан ашыгып җиргә төштеләр,
Салам, мамыклар җыеп йөрделәр.
Кич белән тагын кайтып керделәр.
Таңнар атканда алар сайрады:
Чиф, чиф, чиф дип алар тынмады.

Карлыгачлар да килеп җиттеләр,
Соры балчыктан оя төзеделәр.

Алсу-ак чәчәк атты алмагач,
Сайрап җибәрде шунда сандугач.
Чут, чут, чут дип сайрыйлар алар.
Сайрыйлар алар, уйныйлар алар.

Шундый күңелле бакча яз көне,
Җылы яклардан барча кош килде.

Әширә Кәтиева.

ЭМИЛЬ ЗОЛЯ

Эмиль Золя 1840 нчы елда инженер семьясендә туа. Башта кечкенә хикәяләр яза, аннан соң Золя „Ругон Макары“ исме астында егерме томлы романнар сериясе эшли.

Эмиль Золя үзенең „Тозак“, „Күмер казучылар“, „Жир“ исемле романнарында буржуаз җәмгыят тарафыннан эксплоатацияләнүчеләрнең авыр хәлләрен суратли. Шушы романнарында ук ул тормышның нигезе булган хезмәтне мактый.

Эмиль Золя капитал белән хезмәт арасындагы көрәшне беренче булып әдәбиятка кертә.

1898 нче елда Эмиль Золя Франция республикасының президентына язган „Мин гаеплим!“—дигән мәшһүр хатны иглан итә. Бу хатта ул гаепсез еврей офицеры Дрейфуска яла ягып, аны хәрби трибунал тарафыннан хөкем итүгә үзенең протест тавышын күтәрә. Гаепсез Дрейфусны аклауны сорый. Моның өчен Эмиль Золя акчалата штрафка тартыла һәм хөкемгә бирелә. Шунын аркасында ул Англиягә китәргә мәҗбүр була.

Эмиль Золя 1902 нче елда Парижда үлә.

ЭШСЕЗЛЕК

I.

Иртән эшкә килүчеләр фабриканы ниндидер салкын һәм кайгылы бөлгенлектән караңгылангансыман күрделәр. Залның уртасына урнаштырылган машина үзенең хәрәкәтсез тәгәрмәчләре белән дәшми, тик тора. Бу машинаның сулавы һәм хәрәкәтләнүе, гадәттә, бөтен бинаны җанландырганга күрә, аның тик торуы фабриканы тагы да кайгылырак төскә кертә.

Хуҗа үзенең кабинетыннан чыга да эшчеләргә:

— Бүген шунардан башка эш юк. Заказлар килми. Бөтен эшне туктатырга кирәк,—ди.

Эшчеләр берничә минут йодырыкларын йомарлаган хәлдә, хәзер инде кирәксез булып калган коралларга карап торалар. Башка көннәрдә биредә таңнан ук игәүләр чыжлыйлар, чүкечләр шакылдыйлар иде. Ә менә хәзер инде боларның барсы да күптән йоклагандай булып тоела. Бу хәл киләсе атнага ук йөзләрчә семьяләрнең ашарларына бер ни дә булмаячак дигән сүз. Фабрикада эшләүче берничә хатынның күзләрендә яшь бөртекләре күренә. Ирләр аларга караганда ныграк булып күренергә телиләр. Алар батырлана төшәләр һәм үзара: „Парижда ачтан үлмиләр“,—дип сөйләшәләр. Аннан соң алар бу залдан тыннары бетеп, үлек яныннан чыккандай, кысылган бугаз һәм салкынайган йөрәк белән бер-бер артлы чыгып китәләр. Үлек—ул эш, ул—шәүләсе белән кайгылы рәвештә кара коелып торган телсез, зур машина.

II

Эшче урамда. Ул урам ташына баскан. Бер атна буе инде ул эш таба алмыйча тротуарларны таптый. Ул ишектән-ишеккә йөреп, үзенең мускулларын, кулларын, үзенең бөтен көчен, теләсә генә нинди эшкә, иң пычрак, иң авыр, иң коточкыч эшкә үзен тәкъдим итте. Аның алдында барлык ишекләр дә бикләнделәр.

Бер атнадан бар да бетте. Эшче иң соңгы мәртәбә омтылыш ясап карады. Булмады. Кыенлыклар белән эштән чыгарылган ул коры кул белән әкрен генә кайтып бара. Яңгыр ява, мондый кичне Париж караңгы һәм пычрак. Ул яңгырны сизмичә, бары тик ачлыкны гына сизеп, тиз кайтып җитмәү өчен туктала-туктала яңгыр астында атлый. Менә ул Сена елгасы аркылы салынган күпернең рәшәткәсенә тотынып түбәнгә иелде, зур елга аңа куркынычлы чакыру тавышың ишеттереп, гаҗәп бер тизлек белән ыргыла иде.

Аннан ул үз-үзенә: „Бу куркаклык булыр иде!“—диде дә китте.

Хатыны белән кызы иртән елашканга күрә, ул аларга кичкә икмәк табарга вагдә биргән иде. Төн җиткәнчегә кадәр кайтып, үзенең ялганлаганлыгын аларга әйтергә ул батырчылык итә алмады. Ничек кайтып керүен, түземлелекләрен үстерү өчен аларга нәрсә сөйләячәге турында юлда ул үз-үзенә сорау биреп кайтты, ләкин алар ашамыйча артык түзә алмаячаклар иде. Үзе әле ул тагын да түзәр иде, ләкин хатыны һәм кызы чиктән тыш хәлсезләр.

Бер минут эчендә аның башына: „Әллә хәер сорашыргамы?“—дигән уй килде. Аның яныннан нинди дә булса бикә яки әфәнде үткәндә ул кулын сузарга теләсә, аның кулы агачтай катып кала һәм тыны кысыла. Ул тротуарга баскан килеш хәрәкәтсез кала, ә яхшы киемле кешеләр бу ач кешене исреккә исәпләп, кирегә таба борылалар.

III.

Эшченең хатыны үзенең йоклаган кызын өске катта калдырып, түбәнге каттагы ишек төбенә төште. Ситса күлмәк кигән хатын урамның бозлы һавасыннан калтырана.

Аларның бүлмәләрендә инде берни дә юк, барлык әйберләрен дә ул закладка салып бетергән. Бер атна эшсез тору өйне ташландык хәлгә китерде. Иске-москы җыючыга кичә ул үзенең матрацындагы йонны сатты, хәзер инде матрацның сүрүе генә калды. Болай да көчле ютәлли торган кызына җил өрмәсен дип, ул аны тәрәзәгә элеп куйды.

Ире кайтмый. Яңгыр ява да ява. Ул ишеккә ышыклана, эре тамчылар аның аягы янына тамалар, су тузаны аның юка күлмәге аша үтә. Вакыт-вакыт аның чыдамлыгы бетә. Коеп яңгыр явуга да карамастан, ул ышыкланган җиреннән чыга да урам башына кадәр барып, көткән кешем күренмиме икән дип, карый. Аннан ул чыланып кайта, чәчләрендәге юешлекне бетерер өчен аларны кулы белән сыпыра, бизгәк тоткандагы дерелдәү белән тагы аны көтәргә керешә.

Ниһаят, өйләргә җинаятьче кебек ышыкланган, оялчан ире күренә. Ул аның каршысына атыла һәм кайгылы тревога белән аңа карый.

— Я?—дип мыгырдый ул.

Ул бер нинди дә җавап кайтармый, башын түбән генә ия. Улчак хатын үлек төсле агарына, беренче булып үзе өске катка күтәрелә башлый.

IV.

Өске каттагы кыз йокламый ята. Ул уянган һәм өстәл кырыенда янып бетеп бара торган шәм кисәгенә карап уйга калган. Бу җиде яшьлек кызның йөзендә коточкыч, җан өзгеч булып нидер чагыла, аның сулган һәм җидди сызыкларында олы яштәге хатын төсе күренә. Ул үзе йоклый торган сандыкның кырыена утырган. Аның ялангач аяклары салынып торалар һәм калтырыйлар, ул курчакныкыдай арык нәни куллары белән үзе ябынып ята торган чүпрәкне күкрәгенә кыса. Ул күкрәгендә үзе сүндерергә теләгән нindидер кызулык, ут барлыгын сизенә. Ул уйлана...

Элек ул үзен генә ялгыз калдырсалар курка торган иде, хәзер аңар бар да бер. Кичәдән бирле бер нәрсә ашамаганга күрә ул, анасын икмәк алырга киткәндер дип уйлый. Аның башы шул уй белән тулы. Ул үзенә тигән икмәкне бик кечкенә генә кисәкләргә бүлгәләр һәм аларны ашыкмый гына бер-берләп артлы аузына кабар. Ул үзенең икмәге белән уйнар.

Әнисе кайтты, әтисе ишекне бикләде. Кыз аларның икесенең дә кулларына зур гаҗәпсенү белән карый. Алар бер ни дә әйтмәгәнгә күрә ул да башта бераз көтә, ә аннан соң сузып-сузып:—Мин ач!.. Мин ач!.. дип кабатларга тотына.

Атасы караңгы почмакта, башын куллары белән тоткан килеш, җиргә сеңәрдәй булып утыра, авыр һәм тын үксүдән аның җилкәләре селкенеп-селкенеп китәләр. Ана күз яшен тыеп, кызны йокларга яткыра. Ул аның өстенә бүлмәсендә булган барлык чүпрәк-чапракларны яба һәм акыллы булырга, йокларга куша. Ләкин кыз салкыннан тешен-тешкә бәреп, күкрәгендәге утның тагын да көчлерәк көйдерүен сизеп, тагын да батырлана төшә. Ул әнисенең муйнына сарыла да әкрен генә сорый:

— Әйт әле, әни, нигә без ач?—ди.

А. Алиш тәрҗемәсе.

Кылыч бирегез!

(Кытай баласы җыры)

Күмергә әйләнә яшел урманнар,
Ялкын эчендә туган илебез,
Сезгә әйтәмен: якын туганнар,
Көрәшкә барам, кылыч бирегез!

Болытлар килә күкне капларга,
Туплар актара илем тауларын,
Сугышка китәм, илне сакларга,
Туздырыр өчен дошман яуларын.

Көлгә әйләнә өйләр, бакчалар,
Тыннар кысыла, күлләр кибәләр.
Кәрлә гәүдәле шакшы дошманнар
Гөлләр өстенә агу сибәләр.

Бик күп балалар ятим калалар,
Ач, ялангачлар урам чатында,
Яралар белән газапланалар
Газлы һавада, пуля астында.

Ак японнарга ачу йөрәктә,
Алар бит безнең илне талыйлар.
Җиңәрлек көчләр сизәм беләктә,
Кылыч бирегез миңа, абыйлар!

Фалих Сираҗиев.

Минзәлә шәһәре.

—★—

Сау булыгыз, бозлар!

Бозлар ага. Бүген яше, карты
Җыелганнар елга буена,
Зур игтибар белән бөтенесе
Караганнар бозлар туена.

Шаулый елга. Бозлар актарыла,
Котырынып ага яз суы,
Ашкынулы дәртен бирә безгә
Яз суының көчле ярсуы.

Сау булыгыз, бозлар, сау булыгыз,
Көз җиткәчтен тагын килерсез,
Коньки белән шуар өчен безгә
Шома каток ясап бирерсез!

Ф. Саттаров.

Октябрь районы, Яңа Иглай ТБУМ-е.

Кояш белән бала

— Әй, чү, син кояш!
Кая батасың?
Уйнап туймадым,
Ә син ятасың.

— Ял ит, син иркәм,
Тагы калкырмын,
Син бәхетләне
Нурга манчырмын!

Н. Хәмидуллин.

Казан шәһәре.

1936 нчы елда, Архангельск өлкәсендә, Ак диңгез яры буенда шәһәр төзелә башлады. Бу шәһәр Молотовск шәһәре дип исемләнде. Төзелеш 1944 нче елда тәгәлләнәчәк. Шәһәрдә берничә мәктәп, драма театры, пионерлар дворецы, балалар бакчалары һ. б. бар. РӘСЕМДӘ: Молотовск шәһәре пионерлар дворецендагы хәрби кабинетта пулеметчылар түгәрәге занятие вактында. фото—**В. Шаровский.** (ТАСС фотоклишесе).



Калкукырда кар беткәч*

(„Батыр исемле малай турында хикәяләр“ сериясеннән)

Мирсәй Әмир *П. Новичков рәсемнәре*

V.

Председатель район үзәгенә килеп җиткәндә ут алынган иде инде. Район җир бүлеге мөдире райкомда дигәч, ул туп-туры анда чапты. Райком урнашкан яңа таш йортларның зур-зур тәрәзәләре тирә-якка көчле яктылык балкытып торалар иде. Бәкер райком алдындагы ат бәйләп куюе өчен махсус ясалган киртәгә атын бәйләп куйды да, ашыга-ашыга райком секретаре бүлмәсенә керде. Райком секретаре янында биш-алты кеше бар иде. Бәкер алар арасыннан РИК председателен, район җир бүлеге мөдирен һәм район газета редакторын таныды. Башкалары читтән килгән кешеләр булды күрәсең, Бәкер аларын танымады.

Үзе бик яшь чырайлы булса да, чәче яртылаш агарган райком секретаре Галин, Бәкерне күптән көтеп торган төсле каршы алды. Исәнлек-саулык та сорашып тормастан, эш турында белешә башлады.

— Я, ничек булды, чәчтегезме? Ничә гектар чәчтегез?

— Мин җибәргән сводкаларны сезгә бирмәделәрмени, иптәш Галин?

— Юк, бер нинди сводка алганым юк. Менә әле райзо да зарланып тора үзегездән, вактында сводка бирә белмиләр, эшне хисапка алып бетереп булмый, ди. Я, сөйлә, әле соңга калмадың. Телефон багланышы булган колхозларга озакламый информация бирәбез.

— Райзога да сводка килмәдеме?

— Юк, килмәде,—диде райзо мөдире.

— Шул телефон багланышы булмау суя бит безне, иптәш Галин. Шул булмау аркасында нинди зур уңайсызлыклар...

Галин аңар сөйләп бетерергә ирек бирмәде.

— Беләбез, беләбез, Бәкер, ул турыда сөйләп торуың да артык. Урак өстенә кадәр өлгертербез дип, әйттек бит инде. Нәрсәгә аны тагын кабатлыйсың. Әйтәсе сүзләреңне әйт, аңлашасы эшләреңне аңлаш та, колхозыңа кайт!

— Болай булса, эшләр чуалып тора бит әле, иптәш Галин,—диде Бәкер. Аның тавышы түбәнәйде, гаепле кеше тавышы төсле йомшак, көчсез булып чыкты.

— Нәрсә, нинди чуалыш?—дип сорады Галин.—Саботаж бармы? Кемнәр алар?

— Юк, иптәш Галин, эш анда түгел, без бүген чәчүгә чыктык, бүгенге планыбыз арттырып үтәлде. Чәчү эше бик шәп, тик эш анда түгел...

— Ничек, эш нәрсәдә соң?

— Неужели сезгә бүген безнең колхоздан берәү дә килмәде? Иптәш редактор, бәлки сезгә килгәндер?

— Хәтерләмим.

Бәкер райзо мөдиренә карады.

— Бәлки райзога килгәндер, сезгә генә әйтмәгәннәрдер?

---

* Дәвамы. Башы үткән номерда.

— Юк, әледән-әле сорашып тордым. Сездән сводка китерүче булмады,— диде райзо мөдире.

— Алай булса безнең бер пионерыбыз югалды.

— Ничек?

Бәкер үзенең бүгенниләр эшләвен, Батырны райзога җибәрүен һәм хәзерге вакытта ул малайның кайда йөргәнлеген белмәвенә борчылуын сөйләп бирде.

Райком секретаре, эшнең нәрсәдә икәнен аңлап алгач, Бәкергә ачулана башлады:

— Пионерлар белән шулай эш итәргә ярыймыни? Балаларга карата андый администраторлык ярамаганлыкны гына аңларлык баш юкмыни синдә, коммунист бит син!

Бәкер үзенең гаепсез икәнлеген әйтергә теләде: бер нинди дә административлык күрсәтмәдем мин, Батыр үзе шулай ялгыз гына чыгып китәргә риза булды, дип әйтәсе килде аның. Тик, бу урында акланырга тырышу хәсрәтне җиңеләйтмәвен аңлап, каршы сүз әйтмәде.

— Болай булыр дип уйламаган идем шул, иптәш Галин,—дип кенә куйды.

— Уйларга кирәк иде,—диде Галин, кыска, ачык, кискен тавыш белән сөйли башлады.—Нинди генә эш эшләсәң дә, аның уңай ягын да, тискәре ягын да искә алырга кирәк. Ярый, бар, бер минут кичекмәстән, эзләргә тотыныгыз. Чәчү эшенә дә тоткарлык китерергә ярамый. Бар, кайт, эшлә!

— Кайтуын кайтырмын, иптәш Галин, әгәр дә пионер кайтмаган булса, ул тиз генә табылмаса, ата-аналарына ничек дип җавап бирермен?

— Үзең нәрсә эшләгәнне үзең белмәгән өчен, пионерның ата-анасы каршында гына түгел, партия каршында да җавап бирерсең әле. Бар, эзләгез!

Бәкер башын түбән иеп, бер сүз дә эндәшмичә, райком ишегеннән чыгып китте. Райком секретаре ачу катыш борчылулы чырай белән:

— Пешмәгән!—дип куйды һәм телефон аппаратын борырга тотынды.

VI.

Бәкер райкомга килеп җиткән вакытта, Батырның югалу хәбәре колхоз эчендә таралып өлгергән иде инде. Сания апа үзен-үзе белмичә, такмаклап-такмаклап җылый:

— Әй балакаем, кайларга гына китеп югалды икән, күз нурым. Кайларда гына тилмереп йөри икән, мескенкәем! Шулай ук күрә алмаммы икәнни мин газиземне?!—дип өзгәләнә иде.

Нигмәтҗан абзый башын түбән игән килеш, бер кемгә бер сүз дәшми, башка колхозчылар өчәр-дүртәре бергә җыелышып, үзара сөйләшәләр, бәхәсләшәләр иде.

Батыр югалу хәбәрен ишетеп аякка баскан авыл урамында яңа бер кеше күренде. Башына тирән бүрек кигән, аркасына шактый зур капчык аскан, кулына озын таяк тоткан бу кеше бер капка төбендә сөйләшеп торучы колхозчылар янына килде.

— Нихәл, авылдашлар,—диде ул һәм үзенә җавап биргәнне дә көтмичә, Батырның әтисен сорады.—Нигмәтҗан кирәк иде, кайда икән ул, күрмәдегезме?

— Пәрәмәч!—дип гаҗәпләнеп калды бер колхозчы хатын,—Трантай абзый ич бу!

Башка колхозчылар да ул кешене танып алдылар.

— Трантай шул, каян килеп чыктың!

Трантай дигән кеше аларның соравына җавап бирмәде, үз соравын кабатлады.

— Нигмәтҗанны күрмәдегезме дип сорыйм, ул миңа бик кирәк иде.

— Нигмәтҗан абзый әле генә кәнсәләргә таба китеп бара иде дип, җавап бирде берәү.

Трантай кызу-кызу атлап колхоз идарәсенә таба китте.



Көтелмәгәндә килеп чыккан бу шомлы кешенең Нигмәтҗан абзыйга нинди хәбәр алып килгәнлеген белергә теләп, башкалар да аның артыннан идарәгә таба атладылар. Идарәгә барып җитмәс борын ук Сания апа очрады. Ул такмаклый-такмаклый җылап, үз өйләренә таба китеп бара иде. Трантай аны кычкырып туктатты.

— Сания, алтыным, тукта әле!

Сания апа бу көтелмәгән тавышны ишеткәч, кинәт тукталып калды. Куркуыннан калтырана-калтырана Трантайны көтте.

— Әй, Сания алтыным,—диде Трантай, җыламсырап сөйли башлады,—бәхтең юк икән, бичара хатын...

— Нигә, нәрсә булган?—диде Сания апа, аның тавышы ярым пышылдап чыкты.

Трантай туры гына җавап бирмәде. шундый ук җыламсыраган тавыш белән үз алдына үзе сөйли башлады:

— Бу бала тормас дигән идем шул, бигрәк башсыз бала иде, мәрхүм!..

Сания апа үзен-үзе тота алмыйча алга ташланып, Трантайның ике як кул башына тотынды һәм аны дерелдәтеп селкетә-селкетә сорый башлады.

— Ни булган, ни булган минем балама? Әйт, кайда ул?

— Тыныч бул, Сания, болай сабырсызланып файда чыкмас, Батыргәрәең су төбенә китте... Бәләкәй генә сал белән агып бара иде, коткарырга өлгерә алмый калдым. Кәкере тирәк астындагы шарламакка төшеп китте... Бәхетсез бала...

Аптырашта калган колхозчылар арасыннан бер бабай ашыгып Трантай янына килде һәм кинәт аны җилкәсеннән тотып читкә тартты.

— Син нинди шом таратып йөрисең монда, мәче башлы ябалак!—дип кычкырып җибәрде.

Трантай бер сүз дә эндәшмәде, Сания апа: „Ах балам, балам!“—дип кычкыра-кычкыра идарәгә таба йөгерде.

— Син нинди шом таратып йөрисең монда, мәче башлы ябалак?—дип соравын кабатлады бабай. Трантай тыныч кына тавыш белән җавап бирде:

— Шом таратып йөрмим, Әскәр бабай, күргәнемне генә әйттем. Нигмәтҗанның Батыргәрәе үз күз алдымда Кәкере тирәк шарламагына төшеп, су төбенә китте...

— Үзең җибәрмәдеңме икән син аны су төбенә?

— Алла сакласын! Алла сакласын! Тәүбә диген, бабай...

VII.

Бу Трантай дигән кешенең көтмәгәндә авылга кайтып керүе, җитмәсә шундый хәбәр алып кайтуы барлык колхозчыларның да күңеленә шик салды. Һәркемнең йөрәге тынычсызлана, күңеле борчыла башлады.

Кем соң ул Трантай? Ни өчен колхозчылар аның авылга кайтуын яратмыйлар?

Трантай бозык күңелле кеше, ил өчен зарарлы кеше. Ул эш яратмый, кеше көченнән файдаланып яшәргә өйрәнгән кеше. Сәүдә итеп, кеше алдап, кеше талап баеган — кулак булган ул. Тоташ коллективлаштыру нигезендә кулаклыгы бетерелгәннең соңында, ул авылдан җибәрелмәгән иде. Кеше шикелле эшләп көн күрергә теләсә, аңар бер-ике ел эчендә төзәлергә, эшчән кешеләр рәтенә кереп китәргә мөмкинлек тә бар иде. Ләкин ул алай эшләргә теләмәде, кеше көченнән файдаланып яшәү гадәтен куды, караклык итте.

Узган кышны колхозның атларга дигән онын урлап тотылды да, аны кулга алдылар. Тоттыручы Батыр булды. Аның ат абзарыннан бер капчык он алып чыгып киткәнен Батырдан башка берәү дә күрмәде. Шул вакытта Батыр әйтми калган булса, Трантай тотылмаган да булыр иде. Ләкин Батыр колхоз милке өчен җанын кызганмый торган малай ул. Трантайның усаллыкларын белсә дә, курыкмады, әйтте, шулай итеп, Трантай төрмәгә озатылды.

Аны авылдан алып чыгып киткәндә Батыр мәктәптән кайтып килә иде. Батырны күргәч, Трантай туктап нәрсәдер әйтмәкче булды. Милиция аңар ирек бирмәде. Трантай Батырга акаеп караудан башка бер нәрсә дә эшли алмады. Аның күз карашы Батыр йөрәгендә нindидер бер ямсез тойгы калдырды.

Хәзер ул төрмәдә утыру срогын тутырыпмы икән, яки берәр амнистиягә эләгепме икән, иреккә чыккан иде. Иреккә чыккач туп-туры үз авылына юл

тотты: хәзер инде мин шактый төзәлдем, үз авылыма кайтсам, мине колхозга да алырлар, тырышып кына эшләрмен, дип уйлаган иде ул.

Авылга кайтып җитәргә берничә километр калгач, ул Тәмле елга янында бер тавыш ишетте. Борылып караса, Тәмле елга буйлап җимерек күпер өстендә агып баручы бер малайны күрде. Малайның хәле куркыныч иде. Ул тагы шулай бераз гына агып барса, Кәкре тирәк астындагы шарламак астына төшеп, су төбенә китәчәк. Малай ярдәм сорап тагын кычкырды. Трантай, аны-моны уйлап тормастан, куркыныч астында калган малайга ярдәм итү теләге белән, елга буена ашыкты. Бик тиз килеп җитте, кулындагы таягын ыргытмакчы булды. Ләкин таягын ыргытыйм дип кизәнгән чагында гына күпер өстендә баручы малайның Батыр икәнлеген танып алды да, тукталып калды. Һавага күтәргән таягын җиргә таянды. Аның күңелендә Батырга булган ачуы кузгалды. Бу малай актыгына шул кирәк, китә бирсен!—дип уйлады ул. Тирә-якта башка кеше юкмы икән дип, каранып алды. Берәү дә күренмәгәч, иркенрәк сулап куйды һәм мәсхәрәләп Батырга сүз кушты:

— Нихәл, батыр егет, кататса итәсеңмени?

— Тарантай абзый, таягыңны бир әле,—диде Батыр.

— Ә Тарантай абзыең кирәк булдымыни? Теге вакытта бот буе башың белән минем өстән әләкләп, батыр булган идең бит. Үзеннән олыларга тел озайтмыйлар аны, менә хәзер инде...

Батыр аңа сүзен әйтеп бетерергә ирек бирмәде, ачы тавыш белән кычкырып җибәрде:

— Пошел, кулак эте, сиңа ялынмам!

— Ярый, ярый, молодец, һаман да батыр икәнсең. Озакламый әнә тегендә, Кәкре тирәк астына барып җитәрсең, анда шарламак белән көрәшеп карарсың, кабрең дә шунда булыр, малай актыгы, хуш, бәхил бул, ха-ха-ха...

— Су төбенә китсәм китәрмен, сиңа ялынмам!—диде Батыр. Күпер өстенә ятып, суны куллары белән ишә башлады.

Агым көчле, Батырның кулларына гына бирешерлек түгел иде.

Тарантай аны озак карап тормады. Батырның тиздән шарламакка эләгеп су төбенә китәсен чамалады да, кешеләрнең күрмәсен дип, авылга таба ашыкты, Батырның суга батып үлү хәбәрен таратырга ашыга иде ул.

VIII.

Батыр тиз генә бирешергә теләмәде. Күпер өстенә сикереп төшү белән ашыга-ашыга агып китү шактый хәтәр минут булса да, Батыр артык курыкмады. Үлү турында башына да керер чыкмады аның. Андый гына уңайсызлыктан котылу бик җиңел булыр төсле тоелды. Аз гына да аптырап тормастан, күпер өстенә чүгәләп утырды да куллары белән ишәргә тырышты. Тик шул минутта гына ул үзенең шактый куркыныч хәлдә калганлыгын сизде: күпернең бүрәнәләре бер-берсенә бик йомшак беркетелгәннәр, аз гына хәрәкәт итсәң дә таралып китәргә торалар иде. Батыр уйга калды: күпер таралып китсә, бу тилереп аккан карлы-бозлы суга бишмәтләрең, чабаталарың белән чумсаң, тиз генә йөзеп чыга алмассың, дип куйды.

Аптырап, тирә-якка күз салды. Якын тирәдә берәү дә күренми, тилереп аккан Тәмле елга түбәнгә киткән саен киңәя бара. Нишләргә? Ахрысы бу күпер өстендә озаграк утырырга туры килер, дип уйлады Батыр. Үз тарафыннан үзенә карата әйтелгән шул сүз аның уена тизрәк эшләргә ярдәм итте:

бер урында озак утырырга туры килә икән, утыра торган урынның ышанычлы булуын кайгыртырга кирәк дип, үзенә-үзе киңәш бирде һәм бик саклык белән генә сул аягына тезләнеп, уң аягының чабатасын чиште, үз кулы белән сүс катыштырып ишелгән чабата киндерәсенең ныклыгына кәефләнеп, куана-куана ике бүрәнәне бергә бәйләде. Хәзер тиз генә ычкынып китә алмассың,—дип сөйләнә-сөйләнә аякларын алмаштырды. Уң аягына тезләнеп, сул аягының чабатасын чиште. Беренчесе кебек үк ышанычлы булган икенче киндерә тагын ике бүрәнәне бергә беркетте. Ике киндерәнең артып калган очларын ныклап ялгаганнан соң иркен сулап тәпи басты. Ул инде •берсенә-берсе ярыйсы ук нык итеп беркетелгән дүрт бүрәнә өстендә үзен шактый ышанычлы урында итеп хис итә иде.

— Калганнарыгыз ычкынып китсә дә исем китми,—диде ул күпер читендәге ычкынырга торган бүрәнәләргә карап,— миңа дүрт бүрәнә дә җитәр.

Ләкин иртәрәк тынычланды Батыр. Кул белән ишеп читкә чыгу ул уйлаганча җиңел булып чыкмады. Ишә-ишә кулы туңып беткәндә, сал беленер-беленмәс кенә ярга таба якынлаша башлаган иде, бер зур бозга бәрелеп кире чигенде. Батыр ни заманнан бирле тырышып эшләгән эше җилгә киткәнен күргәч, тагын уйга калды. Үзе уа-уа кулын җылыта, үзе салны чигендергән зур бозга карап уйлана иде ул.

— Ул боз ярга якынрак ага бит,— әгәр дә шуның өстенә сикерсәм, күтәрермикән? Юк, күтәрмәс, Тәмле елга кебек кечкенә суга мине күтәрерлек боз каян килсен? Алай дисәң, бу боз каян килгән? Ул бит үзе селкенмәде дә, минем салны бәреп җибәрде. Зурлыгы да минем сал чаклы бит булыр. Чыннан да каян килгән ул боз? Бер генә дә түгел, андый бозлар күп бит әле... Ә-ә-ә, булыр шул, бер дә гаҗәп түгел, Тәмле елганың бу тәнгәле җәй көне дә, көз көне дә күл кебек зур була, тирән була. Монда бит ул чокырга җыелып тора. Шунда килеп су коенганыбыз да бар бит. Монда мине генә түгел, миннән зурракларны күтәрерлек боз булса да гаҗәп түгел...

— Юк шул, боз-боз инде ул, күпер түгел. Сикерерсең, күтәргән дә булыр, икенче бер бозга бәрелеп ватылып китсә... бултыйх аннары. Әни белми әйтми торгандыр: „Көзге боз көзгедәй булса да күтәрә, язгы боз ястыктай булса да җимерелә“...

Батыр шулай үзе белән үзе киңәшеп, икеләнеп барганда, елгадан артык ерак түгел Батырлар авылына алып бара торган юл буйлап китеп баручы бер арбалыны күрде. Җентекләбрәк карагач, арбага җигелгән җирән атның үз колхозларыныкы икәнен таныды. Атны таныганның соңында арбада ятып баручы кешенең кем икәнлеге Батырга билгеле иде инде. Чөнки ул бүген иртә белән шул җирән атка атланып күрше колхозга арба алырга киткән кешене күргән иде. Шатлыклы, өметле, көр тавыш белән кычкырып җибәрде Батыр:

— Гыймади абзый!

Арбадан җавап килмәде. Җирән ат әкрен генә атлый бирде. Батыр тагын кычкырды:

— Гыймади абзый дим!

Ящик арба төбеннән зур малахай бүрек кигән баш күтәрелде, әкрен генә борылып Батыр ягына карады да яңадан арба төбенә яшеренде. Җирән ат һаман теләр-теләмәс кенә атлап алга баруында дәвам итте. Батыр бераз тын торып җавап көтте. Арбадан җавап килмәгәч, каушаганрак тавыш белән тагын кычкырды:

— Гыймади абзый, коткар, батам бит, чыга алмыйм.

Баш яңадан күтәрелмәде. Батыр яңадан кычкырды. Баш күтәрелмәде. Җирән ат адымын кызулата төште. Гыймади дилбегәсен селкегәндер ахрысы, күп тә үтмәде, җирән ат авылга таба юртып китте.

Аптырашта калган Батыр ни әйтергә белмәде, аның күңеле тулды, җылыйсы килә башлады.

IX.

Арбада ятып баручы кеше чыннан да Гыймади иде.

Гыймади „Тәмле елга“ колхозындагы атаклы ялкау. „Аркылы ятканны буйга алып салмый торган кеше“ диләр аның турында. Аның бүген күрше колхозга арба алырга баруы да ялкаулыгына бәйләнгән иде.

Вакыйга түбәндәгечә булды:

Узган ел көз „Тәмле елга“ колхозыннан элеваторга ашлык илттеләр. Башкалар белән бергә ашлык илтешергә Гыймади да җибәрелгән иде. Ашлыкны тапшырып, кайтыр юлга чыккач, Гыймади үзе утырган арба белән иң артка калды да, ат башкаларга ияреп кайтыр әле дип, ятып йоклады. Тик Гыймадинең ялкаулыгын кешеләр генә түгел, колхоздагы күп кенә атлар да белеп бетергән иде инде: ат йөртүченең Гыймади икәнен сизеп алды исәләр, акрынрак кыймылдый башлыйлар иде алар. Чөнки Гыймади ат җигеп юлга чыгу белән дилбегәсен арба үрәчәсенә эләктереп куя да, үзе сузылып ята. Сузылып яттымы, бетте инде. Йокласа да, йокламаса да торып атын кумый, иренә. Болай да күп эшләгән атларга шул гына кирәк, алар үз җайлары белән юлдан читкә чыгып, үлән ашыйашый баралар.

Ашлык илтеп кайтканда да шулай булды. Кайтырга юлга чыгу белән Гыймади арба төбенә сузылып ятып, йокыга китте. Моны сизеп алган җирән ат башта акрын-акрын, азлап кына башкалардан артта калды. Алдан баручылар күздән югалгач, юл читеннән үлән ашап бара башлады.

Төрле тәмле төшләр күрә-күрә йоклап барган Гыймади „лык“ иткән тавышка сискәнеп уянып китте: арба бер якка таба кыйшаган иде. Гыймади иренеп кенә торып утырды. Арбадан бөтенләй төшмичә генә тирә якка күз салды. Арт күчәрдән чыгып җирдә яткан тәгәрмәчне күрде. Мыгырданамыгырдана арбадан төште. Сүгенә-сүгенә тәгәрмәчкә тотынды. Мышныймышный күчәренә кидерде. Башын бормыйча гына күзләрен йөртеп чәкүшкә эзләде. Якын-тирәдә чәкүшкә дә, чәкүшкәгә яраклы агач сыныгы да күренмәгәч, Гыймади кулын гына селекте һәм яңадан арбасына менеп ятып, җирән атка чыбыркы белән сыдырды. Җирән ат юлга төшеп юртып китте. Гыймади яңадан йокыга китим дигәндә генә тагын „лык“ иткән тавышка сискәнеп уянды. Җирән ат эшнең нәрсәдә икәнен аңлап, әйткәнне көтмичә үк, туктап өлгергән иде инде. Гыймади иренеп кенә арбадан төште. Җирдә яткан тәгәрмәчне күтәреп, мышный-мышный арбага салды: „Авылга барып җиткәч чәкүшкә табылыр әле, шунда кидерермен“,—дип, яңадан арбасына менеп ятты. Бер күчәр өстерәлеп барганын сизеп алган җирән ат, гафу ителерлек сәбәп булды дигәнсыман, бер дә икеләнмичә акрынлый башлады.

Өченче тапкыр йокыга киткән Гыймади җирән ат туктаганга уянды. Тагын ни булды дип торып караса, нәк авыл уртасында аты тугарылып тора иде. Арбадан төште. Тугарылган атны яңадан җикмәкче иде, чөелдерегә өзелгәнлекне күргәч, кире уйлады. Атын бөтенләй тугарып алды, астына чикмән салып атланды һәм урамнан узып баручы бер малайга: „Кара әле, энем, минем арба шунда ятып торсын, озакламый килеп алырмын“ дип, үз авылына таба юнәлде.

Шул калудан калган арба күрше колхозда кышлады. Гыймадига бу турыда берничә мәртәбә әйтелсә дә, колагына алмады. Бу иясезлек өчен Гыймадига гына түгел, бригадирга да эләкте. Председательне дә тыныч калдырмадылар. Бәкерне эшне ахрына кадәр эшләмәүдә, тиз тынычлануда гаепләп, район газетасына яздылар.

Быел яз җитеп, арба юлы төшкәндәй булгач та, Бәкер каты итеп Гыймадинең исенә төшерде.

Арбаны күрше колхоз кешеләре сарайга кертеп куйганнар, арба исән-сау килеш сакланган иде. Гыймадинең ялкаулыгыннан көлә-көлә арбаны биреп җибәрделәр. Ялкауның артык исе китмәде. Кайтыр юлга чыгу белән тагын җирән атны үз җаена куеп, ятып йоклады... Йокы аралаш аның колагына: „Гыймади абзый!“ дип кычкырган тавыш ишетелде. Ул бу тавышка, тәмам уянып өлгергән булса да, башын күтәрергә иренде. Тавыш көчлерәк булып яңадан ишетелде.

— Гыймади абзый дим!

Ни бар икән дип, Гыймади башын күтәрде. Еракта—Тәмле елга өстендә агып баручы Батырны күргәч: „Һи, дуңгыз малай, берәр җүнлерәк кешеме дип торам“,—дип мыгырданды да, яңадан арба төбенә ятты. Батырның: „Гыймади абзый, коткар, батам бит, чыга алмыйм“ дигән сүзләре ишетелсә дә, Гыймади йокы исереклегеннән айный алмады.

урыннан тормыйча гына үрелеп, җирән атка чыбыркы белән сыдырды. Җирән ат юртып китте. Батырның тавышы ишетелми башлады. Гыймади тынычлап яңадан йокыга чумды.

X.

Батырның җылыйсы килүе озакка бармады. Гыймади җавапсыз үтеп китеп күздән югалгач, ул каты итеп тешләрен кысты, күзләрен йомды да, башын селекте. Шуның белән күңел йомшаруы бетте, бары ике күзеннән ике бөртек яш кенә сытылып чыгып калды. Тирән итеп көрсенеп куйгач, Батыр үзендәниндидер бер иркенлек, рәхәтлек хис итте. Ул рәхәтлек—күңелендә туа башлаган йомшаруны җиңү рәхәтлеге иде. Югала башлаган ихтиар яңадан кайтты. Ул активлашып, котылу чараларын эзләргә кереште. Батыр яңа дәрт белән канәгатләнеп, куллары белән салкын суны ишә башлады. Бу юлы боз уңайсызламый торган якка таба ишә иде ул.

Тик бу тырышлык та кирәкле нәтиҗәне бирә алмады. Инде салны җиңеп, читкә таба бордым дигәндә генә икенче яктан тагын бер зур боз килеп бәрелде. Сал яңадан әчкәрәк борылды. Батырның моңар артык исе китмәде, шулай булып чыгасын алдан белеп, көтеп торган төсле, бер нинди ачусыз, тынычсызланусыз туктальш калды. Бармаклары бер-беренә кушыла алмас дәрәҗәгә килеп туңган кулларын бер-беренә ышкып рәткә китерә, тыны белән өреп җылыта башлады.

— Инде ничек итәргә?

Батыр, барасы юл күп бармы әле дигәнсыман, алга карады. Алда зур бер борылыш барлыгы күренде: елга ул урында кинәт кенә сулга борылып китә һәм ул тәнгәлдә аның үзәне уң як ярга якынлаша иде. Аның өстәвенә ул борылмадан соң елга Батырлар колхозына алып бара торган юлга да якынлаша—өмет бар дигән сүз. Борылмадан файдаланып, ярга чыгып булмый калган сурәттә дә, кешеләр йөри торган юлга якын булгач, артык зур куркыныч юк. Юл буенда берәү дә очрамый булмас, кем генә очраса да Гыймади шикелле җавапсыз үтеп китмәс, ярдәм кулын сузар.

Шундый өметле уйлар белән Батыр борылмага якынлашты. Уңайлы минуттан файдаланып калырга тырышып, бөтен көче белән ишә башлады. Яр якынайганнан-якынаеп бара, Батырның аның саен көче арта.

Котылуга тәмам юл ачылып җитте дигәндә генә тагын бер бәлә килеп чыкты. Нак борылмага җиткәндә—суның иң каты аккан җирендә салның киндерә белән бәйләнмәгән башы икегә аерылды. Бүрәнәләр бер-берсеннән аерылгач, бата башладылар. Батырның оеклары белән җиңнәре генә түгел, корсагы да юешләнде. Ишү кайгысы онытылды. Батыр, тарала башлаган бүрәнәләрне аягы белән дә, куллары белән дә эләктереп бергә җыйды. Яңадан таралып китмәсеннәр өчен агым уңаена төшкәнче аларны тотып торырга мәҗбүр иде ул. Шулай азаплана торгач, ярга иң якын китерә торган борылма да артта калды. Елга тагын да киңәя төште. Ике як яр яңадан ерагайганнар иде инде.

Батыр берәр узгынчы очратуны өмет итеп юл ягына карады. Берәү дә күренмәде. Тагын алга карады—борылып-борылып аккан елга өстен чуарлаган эреле-ваклы бозлар ашасыннан еракта утырган яп-ялангач, япа-ялгыз тирәк күренде. Бу тирәкне күрүгә Батырның тәннәре чымырдап китте. Аның моңарчы бер нинди тавышка да игтибар итми килгән колакларына куркынычлы шаулау иштелде. Яшен яшнәтеп, күк күкрәтеп, иген кырларын харап итеп килә торган боз яңгырын хәтерләтә торган шомлы шаулау иде ул.

— Кәкре тирәк шарламагына җитеп киләм,—дип куйды Батыр. Аның моңарчы булган тынычлыгы югалды. Ашыга-ашыга тирә ягына каранды. Ярдәмгә килүче берәү дә күренмәде. Батыр үзенә-үзе приказ бирде:

— Бөтен таяныч үзеңдә, Батыр, тырыш!

XI.

„Тәмле елга“ колхозыннан берничә километр ераклыкта Кәкре тирәк шарламагы бар. Ямле җәй көннәрендә бу шарламак колхозчыларның, бигрәк тә пионерларның яраткан урыннары була. Утау вакытларында, урак өсләрендә кызу кояшка янып, тиргә баткан кол-

хозчылар шушы метр ярымнан биегрәк яр башыннан коелган шарламак астына кереп коеналар, хәл алалар. Шарламак хәл кертә, арган тәннәргә яңа көч бирә, төшкән күңелләрне күтәрә.

Шарламак астында Тәмле елга һәр вакыт тирән була. Су күп булганлыктан, ул җирдә җәй буена балык үрчи. Малайлар бу урында кармак белән балык тоталар. Көннәр буена су коеналар. Шарламак һәркемне куйнына ала, һәркемне рәхәтләндерә, һәркемне үзенең чиста, салкын суы белән башыннан сыйпый, иркәли. Ул чакларда шарламактан да ягымлы, аннан да сөйкемле урын юк төсле тоела.

Ә хәзер, Тәмле елганың язгы кар сулары белән кушылып, бозларга болганып ташыган вактында, Кәкре тирәк шарламагы куркыныч. Төрле авыллардан агып килеп әшәке тиресләр, чүпчарлар һәм җирдән күтәрелгән балчык белән болганып, ямсез төскә кергән су коточкыч зур булып, коточкыч көч белән үкереп, түбәнгә кадала. Зур-зур бозлар бу коточкыч шарламак астында берсе өстенә берсе кадалып, челпәрәмә киләләр, вак кисәкләргә бүленеп, юкка чыгалар. Шарламак кемгәдер бик каты ачуланган төсле өзлексез үкерә.

Ә шарламак өстендә, дүрт-биш сажин гына үрдәрәк, япа-ялгыз, шыр ялангач кәкре тирәк тора. Ул бер туктаусыз ямсез тавыш белән улый.

XII.

Батыр барлык көченә тырышып ишсә дә, котырып аккан язгы ташкынны җиңү кыен иде. Аның хәле куркынычланганнан куркынычлана барганда, елгадан ерак түгел юл буйлап баручы озын таяклы бер җәяүле күренде. Батырның күзләрендә өмет уты кинәт яшнәде. Тик ул озакка бармады, аптырау билгесе белән алмашынды. Башына тирән бүрек кигән, аркасына шактый зур капчык аскан, кулына озын таяк тоткан бу кешенең Трантай икәнлеген танып алды Батыр. „Ни эшләргә, Трантайдан ярдәм сораргамы, юкмы?“— дигән уйга калды ул. „Ул бит кулак, карак, ил дошманы, мин аны кулга алдырттым, ә хәзер...

Озак уйларга вакыт тар иде. Батыр, үз-үзенә хисап бирмәстән, кычкырып җибәрде.

— Трантай абзый!

Трантайның ярдәм итмичә үлем аузына ташлап китеп баруы Батырның ачуын гына кабартты. Ул ачудан янып кузгалган яңа дәрт белән суны ишә башлады. Ул Трантайга яңадан күтәрелеп карамады.

Хәл куркынычланганнан-куркынычлана бара, тирәк якыная иде. Батыр инде ярга чыгып өлгерүдән өмет өзде. Шул язгы ташкын вактында су эчендә калган тирәккә ничек булса да эләгеп калырга кирәк дип, салны тирәк янына борырга тырыша башлады. Сал күзгә сизелерлек тизлек белән тирәккә якыная бара, батыр аның саен өметләнеп тырыша иде.

Менә хәзер менә хәзер җитә... Күп булса ун-унбиш метр калгандыр, тагын аз гына якынаеп өлгерсә, сал тирәк турысына киләчәк. Ну-у! Һу-у-п!..



Батырның өмет уты гөрләп кабынырга торганда тагы баягы бәлә килеп чыкты. Читкә таба ишү аркасында салның агымы бераз акрынайганлыктан, бер зур боз куып җитеп, тирәк белән ике арага кердә дә салны кирегә этеп җибәрде. Ул арада тирәк турысына җитәргә ике-өч метрдан да ары юк иде инде.—Тирәкне үтеп китсәң, беттем дигән сүз. Батыр сал өстенә ятып ишкән җиреннән сикереп торды. Иң элек тирәккә, аннан соң шуңа таба аккан боз өстенә карады да кепкасын басыбрак киде. Тезләрен пружиналандырып чүгәләде һәм мәче җитезлеге белән боз өстенә сикерде. Боз бераз янтаеп яртылаш суга батты, ләкин бирешмәде. Батырның килеп төшү көче белән тирәккә якынрак кына килде, һәм тирәкнең кыйшаеп чыгып тора торган ботагы астыннан үтеп китә башлады. Батыр кирәкле минутны ычкындырмады, читкә чыгып торган ботакка куллары белән тотынды. Боз да, боздан ерак түгел агып барган сал да шул ук минутта шарламакка барып кадалдылар. Батыр куллары белән тирәк ботагына асылынган хәлдә калды.

XIII.

Батыр актив физкультурник булганга, турникта уйнауда да алдынгыларның берсе иде. Ботакка асылынып калгач, ул үзенең турникта уйный белү һөнәрен файдаланып, аякларын югары күтәрде дә ботакның өстенә чыкты. Ботакның өстенә атланып утырган килеш, акрын гына тирәкнең үзәгенә таба шуышты. Тирәкнен өчкә аерылган җиренә килеп, кояшка каршы утырды. Аягыннан оегын салып сыкты да аны киптерергә элде. Салкын суда килеп туңган аяклары яз кояшында рәхәтләнеп җылына башладылар.

— Бу да булды,—дип уйлады Батыр.— Инде ни эшләргә?

Ташкын эчендә калган бу тирәк башыннан котылу өчен иң элек юлдан берәр кеше үткәнен көтәргә, аннан соң ул кешенең авылга кайтып, көймә җибәртүен көтәргә кирәк иде. Батыр моны сизенде.

— Бу агач башында байтак утырырга туры килер, ахрысы,— дип куйды.

Һәм чыннан да Батырга тирәк башында шактый вакыт үткәрергә туры килде. Тирәк башында узган берничә сәгать эчендә аның башына бик күп уйлар кереп чыкты. Иң элек Трантай турында уйлады ул.

— Дөньяда нинди алама кешеләр бар, ә? Мин бит аны теге вакытта кызганган да идем. Авылдан киткән вакытта күзләрен шундый ямсез акайтып караганын күргәч, йөрәгем әллә ни эшләп киткән иде. Үземнең аны тотты руыма үкенгән дә сыман булдым шикелле. Ничектер, ул да барыбер кеше кебек күренде, кызганыч тоелды. Ә ул нинди явыз! Минем үлем алдында калганымны күргәч, шатланды гына... Кая бара икән соң ул? Ничек ычкынган?

Бәлки ул тагын безнең авылга кайткандыр. Бәлки колхозга керергә уйлый торгандыр. Юк, ул безнең колхозга керә алмас! Мин аның бу явызлыгын



Рәсемдә: Нева елгасында боз.

Н. Демешенко фото-этюде.
(ТАСС фотоклишесе).

сөйләрмен. Колхозда андый кеше булмаска тиеш диярмен... Дөньяда нинди алама кешеләр бар... Социализм бөтен җир шарында җиңгәч, коммунизм булгач, дөнья йөзендә андый кешеләр калмас. Нинди яхшы булыр ул чакта...

Батырның уйлары шул уңайдан Гыймадига күчтеләр:

—Гыймади абзый бар тагы!.. Ничек итеп кеше шул чаклы ялкау була ала? Ул бит минем батып үлү алдында калуымны күрә торып, урыннан кузгалырга иренде... Ялкау гына микән ул? Әллә ул да миңа үч саклый микән? Стена газетасында мин аның сурәтен ясаган идем бит, әллә шуны исендә тотып, минем үлүемне теләдеме икән? Андый кешеләр ничек дөньяда тора алалар. Аларга дөньяда яшәүнең ни кызыгы бар икән? Абау, әшәке кешеләр. Коммунизм булгач, андый ялкаулар да булмас...

Кешеләр!.. Кешеләр!.. Башка кешеләрнең дә шундый әшәке яклары, кешенең ачуын китерә торган яклары була микән? Әгәр шунда, мин суда агып барган чакта, Бәкер абзый килеп чыкса, ни эшләр иде икән? Нәрсә дип әйтер иде икән?.. Әгәр дә бу урында тирәк булмаган булса, мин ни эшләр идем. Бу тирәкнең биредә үсүе шулай кирәк булган микәнни?..

Батыр үзен үлемнән коткарып калган тирәкне карый башлады. Җентекләп караганда бу тирәк искиткеч ямсез тирәк иде. Ул кәкере-бөкере, катлаулы-катлаулы булып ускән, бик күп урыннары зур-зур орылар белән капланган; бер дә кирәкмәгән урында ямсез-ямсез ботаклар чыгып торалар. Аның кыяфәтенә карап кына нинди агач икәнен дә белерлек түгел... Ни өчен бу кадәр буталчык, ямсез булган икән соң бу тирәк?

Батыр үзенең ишеткән-күргәннәрен, мәктәптә чакта укыганнарын исенә төшереп, тирәкнең ямсезлегенең сәбәпләрен эзли башлады. Ялгыз үскәнгә күрә шулай тупас, шулай тәртипсез, шулай ямсез булган ул. Ялгыз үскән агачлар һәр вакыт шулай, урманда үскән агачларга ошамыйлар. Агачлар бергә үскәндә генә шома булып үсәләр. Берберсе белән ярышып, матур булып үсәләр. Әгәр дә агачлар берсен-берсе күрә торган, берсен-берсе аңлый торган булсалар, бу тирәкне башка агачлар бер дә яратмаслар иде. Ул шундый ямсез, шундый тәртипсез, шундый алама киемле дип, аны яманлап сөйләрләр иде... Ә шулай да, бу ямсез тирәк булмаган булса мин үлгән булыр идем. Ни өчен ул алай? Кешенең тормышы шулай, ялгышып, урынсыз үскән тирәкләргә дә мохтаҗ микәнни! Юк, алай булмас, кешеләр дә бит, барсы да минем кебек түгелләр. Мин үзем әзрәк шушы тирәккә ошаганмын. Бәкер абзый бит миңа бер иптәш белән барырга кушты. Мин үзем бер ялгызым китәргә теләдем. Бәкер абзый миңа бу күпердән чыгарга кушмады. Мин аны тыңламадым, үземчә эшләдем. Кешечә эшләгән булсам, бу ялгыз тирәккә мохтаҗлык булмаган булыр иде... Чынлап та, мин шушы тирәккә ошаганмикәнни? Мине дә башка кешеләр яратмый микәнни? Берәү дә мине коткарырга килми... Әйе, мин булдыксыз, мин үземә тапшырылган бурычны үти алмадым. Хурлык, хурлык!..

(Ахры киләсе номерда).

М. В. Ломоносов

Русның бөек галиме һәм язучысы Михаило Васильевич Ломоносовның үлүенә быел 16 нчы апрельдә 175 ел тулды. Рус фәнен һәм әдәбиятын алга җибәрүдә бик зур эш эшләгән бу кешене А. С. Пушкин „Беренче рус университеты“ дип атады. Дөрестән дә, Ломоносов фәннең бер өлкәсендә генә галим булмыйча, бик күп фәннәрне белүче һәм аларны алга җибәрүче кеше. Лавуазье дигән галимнән 40 ел элегрәк ул әйберләрнең саклану принципын таба. Майер дигән галимнән 90 ел элек ул энергиянең саклану законы турында үз фикерләрен әйтә. Жорж Хэлдан 180 ел элек кояш тапларының төзелешен аңлатып бирә.

Шуның белән бергә Ломоносов рус телендә матур гына шигырьләр дә яза. Арктиканы өйрәнү кирәклеген күрсәтә. Моннан башка да Ломоносовның хезмәтләре күп. Ләкин үз вактында Ломоносовның фәнни эшләренә игтибар итмиләр.

Ана телендә укуга зур әһәмият биреп, Ломоносов үзенең әсәрләрен рус телендә яза, укучыларын рус телендә укыта. Ломоносов яшәгән чорда фәнни әсәрләрне рус телендә сирәк язганнар. Ломоносов башлап җибәргән зур эш бик тиз җәелеп китте. Рус фәне Менделеев, Пржевальский, Мечников, Лобачевский кебек зур галимнәрне, рус әдәбияты Пушкин, Лермонтов, Некрасов кебек зур шагыйрьләрне бирде.

Менә шул галим М. В. Ломоносов 1711 нче елда Архангельск өлкәсенең, Денисовка

(хәзер Ломоносово) авылында туа. Ул атасы белән бергә диңгездә балык тотып һәм хәйван аулап үсә. Төньяк табигате белән сокланырга өйрәнә, аның кыен шартларында чыныга. Укырга-язарга өйрәнер өчен Ломоносовка бик нык тырышырга туры килә, чөнки ул вакытта укый-яза белүчеләр бик сирәк булган. Үз авылларында укыр өчен Ломоносов бары тик өч китап кына таба. Алар—грамматика, дин һәм арифметика китаплары.

1730 нчы елда Ломоносов Архангельскидан җәяүләп Москвага укырга киткән. Ул вакытта крестьян балаларын укырга алмаганнар. Шуңа күрә Ломоносов үзен дворян баласы дип күрсәтеп, „Словян-грек-латин мәктәбе“нә укырга керә. Көненә өч тиен стипендия алып, аның бер тиененә икмәк, бер тиененә квас, бер тиененә кәгаз һәм башка әйберләр алып, биш ел буенча шул мәктәптә укый.

1735 нче елда Москвадагы мәктәпләрдән иң яхшы укучыларны академиягә укырга алырга булалар. Шулар арасында Ломоносов та эләгә.

1736 нчы елда Ломоносовны чит илгә—Марбург университетына химия һәм металлургия фәннәре буенча укырга җибәрәләр. Чит илләрдә дә төрле газаплар күреп укыгач, Ломоносов 1741 нче елда Россиягә, Петербургка кайта. Чит илдә булган вакытта ук М. В. Ломоносов үзенең әсәрләрен яза башлый. Ул „Хотинны алу турында ода“ исемле шигырь яза. Чит илләрдән М. В. Ломоносов зур белгеч булып кайта.

Петербургка кайткач, М. В. Ломоносов академиядә эшли башлый һәм соңгы көненә кадәр шунда эшли. Күп кенә китаплар яза. 1748 нче елда аның „Риторика“ исемле китабы, 1755 нче елда „Грамматика“ исемле китабы басыла. Болардан тыш ул тагы химия, физика, металлургия, география, астрономия фәннәре буенча күп кенә әсәрләр язды, бик әһәмиятле фикерләр әйтеп калдырды.

Михаило Васильевич Ломоносов 1765 нче елның 16 нчы апрелендә үлә.

Ломоносов үзенең ватанын, халкын бик ярата иде. Халык арасыннан Платоннар, Ньютоннар чыгуга ул ышана. Ломоносовның бу уйлары хәзер расландылар. Хәзер безнең туган илебездә яшәүче һәрбер халыктан зур галимнәр үсә.

Хәмит Кави.

Җаваплы редактор **Г. ХӘБИБУЛЛИН.**

Ответств. редактор **Г. ХАБИБУЛЛИН.**

Заказ № 1617. 2 табак. Табакта 70.700 знак. Главлит вәкиле № 328. Производствога бирелде 7/IV—40 ел. Басарга кул куелды 29/IV—40 ел. Тираж 6652. Кәгаз форматы 70×108.

Александров исемендәге типография. Казан, Бауман урамы, 19. 1940 ел.

Күңелле ял

Кызыл алмалар

Җәй ахрындагы матур көннәрнең берсендә безөчәү —Хәмзә, Шмидт һәм мин —бакчадан өчебезгә бер капчык алма җыйдык һәм „Соңыннан барлык алмаларны өчебезгә дә бер тигез бүләрбез“ дигән карарга килеп, алма агачы астына йокларга яттык. Минем иптәшләр бик тиз йокыга киттеләр, ә мин йоклый алмыйм—ашыйсы килә.

Озак уйлап тормадым: капчыктагы алмаларны өч өлешкә бүлдем дә, үземә тигән алмаларны ашап, тагын йокларга яттым.

Күп вакыт үтмәгәндер, мин уяндым һәм иптәшләрне дә уяттым. Хәмзә йокылы күзләре белән безгә карап: „Малайлар, гаепләмәгез, мин сез йоклаганда уянып, барлык алмаларның өчтән берен ашадым“,—дип куйды.

— Ничек алай? Мин дә яңа гына шулай эшләдем ич . . . Болай булгач, Гали генә ашамаган булып чыга, —дип кычкырып җибәрде Шмидт һәм алмалы капчыкны миңа сузды:

— Гафу итәсез, иптәшләр,—дидем мин үз чиратымда,—мин сездән алдарак, нак сезнеңчә эшләдем, һәм шуның өчен бу алмалар сезгә булырга тиеш. Икәү теләсәгез ничек бүлегез.

— Үткән эшне кире кайтарып булмый инде, малайлар, әйдәгез, бу калган алмаларны да өчкә бүләбез дә—эш бетә,—дип тәкдим итте Хәмзә. Без риза булдык һәм калган алмаларны өчебезгә дә тигез итеп бүлеп, ашый-ашый өйгә кайтып киттек.

Кемгә күпме алма тигәнен һәм барлыгы күпме алма булганын укучылар, минемчә, үзләре дә бик тиз төшенерләр.

Ягез, уйлап карагыз әле!

М. Гәрәев.

ҖАВАПЛАР

ГЕОГРАФИК БАШВАТКЫЧ

(№ 1)

Сибирьдәге тау—Алтай, СССР нын Европа өлешендәге шәһәр—Тула, Тувин халык республикасының башкаласы—Кызыл, Америкадагы дингез каналы—Панама, Латвиянең башкаласы—Рига. Казахстандагы таш күмер учагы—Караганда, Сибирьдәге зур елга—Лена, Африкадагы зур өлкә—Судан, Сибирьдәге бер елга—Яна, Ока елгасы буендагы шәһәр—Касыйм, Казахстандагы күл—Батыр.

Географик башваткычта җәя эчендә бирелгән сорауларга менә шушы сүзләрне кую белән сез аның тулы җавабын таба аласыз.

ГЕОГРАФИК КРОССВОРД

(№ 2)

Горизонталь буенча:

1. Прага. 6. Лена. 7. Руан. 9. Дон. 12. Нант. 14. Нева. 15. Уз. 16. По. 17. Гавр. 20. Майн. 22. Буг. 24. Ухта. 25. Оран, 26. Турин.

Вертикаль буенча:

2. Риад. 3. Горн. 4. Берн. 5. Кале. 8. Онега. 10. Ош. 11. Марна. 13. Тур. 14. Ном. 18. Вахш. 19. Чу. 21. Арал. 22. Баку. 23. Гори.

БӘЯСЕ 50 ТИЕН
ЦЕНА 50 КОП.

„ПИОНЕР КАЛЯМЕ“

ЕЖЕМЕСЯЧНЫЙ ЖУРНАЛ ПИОНЕРОВ И ШКОЛЬНИКОВ

ОРГАН ОБКОМА ВЛКСМ И НАРКОМПРОСА ТАССР.